# Түгәрәк уен

ТАТАР ХАЛЫК ИҖАТЫН ЯКТЫРТУЧЫ МӘГЪЛҮМАТИ-ПОПУЛЯР АЛЬМАНАХ 1/ 2026

**Борынгы элмә – тамбур җөе барлык төрки халыкларның чигешләрендә дә очрый, әмма ул бары тик татарларда гына өйдәге кул эше буларак кына түгел, ә профессиональ һөнәрчелек буларак үсеш ала. Аны еш кына «татар чигүе» дип йөртәләр**







**Фотолар Татарстан Республикасы Рәисе рәсми сайтыннан**



# Креатив индустриягә – яңа үрләр

ЦУМның җисеме үзгәрсә дә, исеме калды. Төбәктә бердәнбер уникаль осталар үзәге (Центр уникальных мастеров) хакында бүген шулай дибез. Сәүдә үзәген сатып алып, аны һөнәрчеләргә тапшыру идеясен Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Миңнеханов күңелендә күпме йөрткәндер, анысын әйтүе кыен, әмма 2023 елда яңгыраган фикер бүгенге көндә инде чынбарлык. Әле кайчан гына «скелет» хәлендә калып, диварларында җилләр уйнап утырган бина реконструкциядән соң инде һөнәрчеләр карамагында. Үзәк стратегик проект буларак, креатив икътисадның пилот моделе. Аңа Татарстанның мәдәни кодын саклау һәм үстерү бурычы йөкләнә.

Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге соңгы ике елда уникаль осталар үзәгенә потенциал резидентларны сайлап алу максатында даими рәвештә халык һөнәрчеләре арасында сәнгать эксперт Советлары уздырып килә. Яңа үзәктә әлегә 79 оста, аларга остаханәләр ташламалы шартларда бирелә, ягъни өч ел дәвамында аренда бәясен түләмәячәкләр. Җитәкчелекнең алга таба җирле осталар белән генә чикләнмичә, Россия төбәкләреннән һәм чит илләрдән алтын куллы һөнәрчеләрне җәлеп итү нияте дә юк түгел.

1 март көнне Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Миңнеханов биредә һөнәрчеләр белән очрашты. Үзәк буйлап экскурсияне Татарстан Республикасы мәдәният министры Ирада Әюпова уздырды. Гомуми мәйданы 50 000 кв. м булган объектның әлегә 30 000 кв. метрлы тарихи блогы эшли башлый. 79 резидент 68 остаханәдә халык сәнгате һөнәрчелегенең 18 юнәлеше буенча иҗат итәчәк.



Осталык дәресләре, күргәзмәләр уздыру өчен дип тәгаенләнгән, җиһазландырылган урыннар да тел-теш тидерерлек түгел. Якты, иркен, бөтен нәрсә энәдән-җептән төшкән – өр-яңа. Кадрлар әзерләү, креатив индустрияне популярлаштыру – алга куелган төп бурычларның берсе булып тора.

Музей, лекторияләр, чәк-чәк, гөбәдия, өчпочмак кебек милли ризыкларга өстенлек бирүче җәмәгать туклануы урыннары – ресторан, каһвәханә эшлиячәк. Балалар өчен уен мәйданчыклары шулай ук каралган.

Май аенда 20 000 кв. м мәйданлы яңа эшлекле блок файдалануга тапшырылачак.



# ЭЧТӘЛЕК

## ТАТАР ДӨНЬЯСЫНЫҢ ТРАДИЦИОН МӘДӘНИЯТЕ ЯҢАЛЫКЛАРЫ




4 **М. Җәлилнең тууына 120 ел тулуга багышлап**


7 **Россия мәдәнияте көннәре**


## ҺӨНӘРЛЕ ҮЛМӘС...




10 Г. Вәлиева-Сөләйманова
**Татарның элмә (тамбур) җөе: гасырлар аша бүгенгәчә**


## ӘДӘБИ МИРАС




18 Л. Мөхәммәтҗанова
**XVII–XVIII йөз татар риваятьләрендә фольклор һәм тарихи хәтер бәйләнеше**

23 Г. Төхвәтова
**Тукай китаплары нәшер ителү тарихыннан** *(1907-1914 еллар)*



Түгәрәк уен
№1 (59) / 2026


*Халык зур ул, көчле ул, дәртле ул,*
*моңлы ул, әдип ул, шагыйрь ул.*
Г. Тукай


16+ Татар халык иҗатын яктыртучы мәгълүмати-популяр альманах

**Гамәлгә куючылар:**
Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы каршындагы Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге



**Редколлегия:**
Ирада Әюпова
Марсель Бакиров
Тәлгат Галиуллин
Дания Заһидуллина
Марс Тукаев
Фәрит Юсупов

**Директор:**
Алсу Равил кызы Мифтахова
**Баш мөхәррир:**
Расиха Габделбәр кызы Исмәгыйлова

**Альманахның иҗат төркеме:**
Гөлназ Латыйпова
Илнара Гәрәева

**Дизайнер һәм биткә салучы**:
Диләрә Нәүрузова



Альманах 2020 елның 13 ноябрендә Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәттә (Роскомнадзор) ПИ № ФС77-79590 номеры белән теркәлгән.
Журнал өч айга бер чыга. Бәясе иркен.

Кәгазь форматы 60×90 ⅛.
Күләме 8 басма табак.
Басарга кул куелды: 11.03.2026
Чыгу көне: 26.03.2026
Заказ: № 60. Тираж: 1000 данә.

**Редакция һәм нәшер итүче:**
420021, Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Казан, Тукай ур., 74 а.
**Хатлар язар өчен адрес:**
420015, Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Казан, Пушкин ур., 66/33, тел.: 293-27-99.
E-mail: tugarakuen@mail.ru

Отпечатано в ИП Селиванова А.Г.
420015, Российская Федерация, Республика Татарстан, г. Казань, ул. Галактионова, 14
тел.: +7(843)2382449
E-mail: Orange_k@list.ru




Кульъязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.
Күчереп басканда, «Түгәрәк уен» альманахына сылтама ясау мәҗбүри.


**Тышлыкта:** Хатын-кыз җиңсәләре фрагменты. Элмә чигүе. XX гасыр башына караган үрнәкнең реконструкциясе.
**Автор Л.Фәсхетдинова.**


© «Түгәрәк уен», 2026

МИФОЛОГИК МИРАС



30 Г. Гыйльманов
**Татар аты**

ХАЛКЫБЫЗНЫҢ КҮРКӘМ ЙОЛАЛАРЫ



36 Р. Фаизова
**«Зөбәрҗәт»ләр кайдан да, «Төннек бәйрәме» кайда?**

КЫЙБЛА



44 А. Фәйзрахманов
**Рухи мирас сагында**

СӘХНӘ

48 Р. Фаизова
**Мәктәптә халык театры?!**

ОСТАХАНӘ: КИЕЗ БАСУ



52 Г. Исмәгыйлева
**Җылы да, йомшак та**

БЕЗ, БЕЗ, БЕЗ ИДЕК...



55 Э. Шәрипова
**Боз озату**

57 **Әкият илендә**
(Җыр)

ӨЙ КҮРКЕ – АШ



58 **Ашлы өйдә бәрәкәт бар**


59 **Казан мантые**

ЯЛ СӘГАТЬЛӘРЕНДӘ

62 **Бергәләп бизибез!**




# М. Җәлилнең тууына 120 ел тулуга багышлап



Каһарман-шагыйрь Муса Җәлилнең (Муса Мостафа улы Җәлилов 1906–1944) тууына 120 ел тулуга багышланган чаралар ел буе дәвам итәчәк.

Муса Җәлилнең музей-фатиры юбилей елына багышлап күчмә күргәзмә булдырган. Өч стендка урнаштырылган материаллар Татарстан Республикасының Милли музее тупланмасыннан алынган фоторәсемнәр, документлар, шигырьләрдән өзекләр белән тулыландырылган. Шул чорга аваздаш әйберләрне күрсәтү өчен подиумнар, шагыйрьнең биографиясе, шәхси әйберләре турында сөйләүче видеолар белән җиде QR-код куелган.

Быел ул Татарстан Республикасы Рәисенә, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының коллегия утырышында, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясендә һәм КФУның Филология һәм мәдәниятара коммуникацияләр институтында, Бөтендөнья татар конгрессы оештырган әдәби конкурста катнашучыларга да (800 кеше) күрсәтелде. Камал театры сәхнәсендә каһарман-шагыйрьнең рухи ныклыгын күрсәтүче «Җәлил» театральләштерелгән мюзиклын карарга килгән тамашачылар да күргәзмә экспонатлары белән якыннан танышты. 8 март көнне күргәзмә Казан Аренада «Рубин» һәм «Краснодар» футбол командалары җанатарларына тәкъдим ителде.




**Татарстан Республикасы Милли музеенда Төп нөсхә күнə.**
**«Моабит дәфтәрләре»н шагыйрьнең кызы Чулпан Җәлилова алып чыга. 15 февраль, 2026 ел**



**Күчмә күргәзмә**

Проект алга таба Минзәләгә (М. Җәлил 1941 елда анда хәрби-сәяси җитәкчеләр – политруклар курсын тәмамлый), аннан Кайбыч районына китәчәк. Күчмә күргәзмә маршрутында Оренбург белән Мәскәү дә бар.

– Юбилей елына әзерлекне без җиңелчә төзекләндерү эшләре белән башлап җибәрдек, юкса соңгы 12 елда берничнди ремонт та үткәрелмәгән иде. Музейның мемориаль өлешендә идәннәр буялды, күргәзмә залында яңа пәрдәләр элдек, – ди Муса Җәлил музей-фатиры мөдире Ленария Мөслимова. – Чараларны «Ромашка 2.0» клубы форматында иҗади татар яшьләре очрашуы белән башладык. Татарстан Язучылар берлегенең, Г. Камал исемендәге театрның яңа буыны, «Tatarkino», «Tatforum», «Ялкын» журналы, музыкантлар белән бергәләп Муса Җәлил мирасына нигезләнгән уртак проектлар турында фикер алыштык. Элеккеге пластинкалардан Муса Җәлил шигырьләре һәм Салих Сәйдәшев музыкасы яңгырады. «Ватаным Татарстан» газетасы (М. Җәлил кайчандыр шунда эшләгән) коллективы белән берлектә шагыйрьнең Иосиф Сталинга, дуслары Әмирхан Еники һәм Хәсән Туфанга язган хатларын укыдык. КФУның Филология һәм мәдәниятара коммуникацияләр институты белән берлектә уза торган «Җәлил укулары» фәнни конференциясе дә үзара хезмәттәшлекнең уртак җимеше.

Музей-фатирның музыка салонында традицион форматта иҗади концертлар да үткәрелә. Казан дәүләт мәдәният институты һәм И.В. Әүхәдиев исемендәге Казан музыка көллияте белән берлектә оештырылган тамаша шагыйрьнең композитор Нәҗип Җиһанов белән дуслыгына багышланды. Студентлар өчен махсус булдырылган интеллектуаль викторина уены М. Җәлилнең иҗатын, тормыш юлын өйрәнүгә зур этәргеч бирә.

Бүгенге көндә М. Җәлил әсәрләре буенча шәһәр буйлап җәяүле экскурсияләр уздырыла һәм «Кызыл Ромашка 2.0» клубы кысаларында яшь энтузиаст режиссерлар тарафыннан кызыклы тамаша әзерләнә.

**Тиздән яшь дизайнерлар өчен ачык конкурс игълан ителәчәк.**

**Конкурс Муса Җәлилнең фатир-музееның күргәзмә мәйданын яңача күзаллауны максат итеп куя.**

Дизайнерлар музей эшчәнлеген, шагыйрьнең тормыш юлын, иҗатын тирәнтен аңлысын өчен махсус семинарлар уздырылачак.

Конкурска тәкъдим ителгән эшләр җәй көне шәһәрнең Вахитов районында Щапов, Мөштәри, Горький һәм Гоголь урамнары киселешендә урнашкан Лядский бакчасында ачык һавада күрсәтеләчәк.

# Россия мәдәнияте көннәре



Оман Солтанатында узган Россия мәдәнияте фестивале кысаларында Татарстан Республикасының бай һәм үзенчәлекле мәдәнияте тәкъдим ителде. Әлеге вакыйгага багышлап «Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе Бөтендөнья татар конгрессы белән берлектә «Тере мирас: Иделдән Култыкка кадәр» дип аталган киңкырлы күргәзмә оештырды. Әлеге проект чын-чынлап Идел ярлары белән Оман Култыгы яр буйларын тоташтыручы мәдәният күперенә әверелде һәм халыкара аудиториягә татар халкының күп гасырлык милли йолаларын, гореф-гадәтләрен тирәнтен аңларга мөмкинлек ачты. Анда XIX гасыр ахыры – XX гасыр башындагы татар костюмнарының реконструкцияләре, татар шәмаилләре һәм үзебезнең милли ризыкларыбыз тәкъдим ителде.

Татарстан стенды белән Россия Федерациясенең Оман Солтанатындагы гадәттән тыш һәм тулы вәкаләтле илчесе Олег Владимирович Левин һәм башка мәртәбәле кунакларның танышуы әһәмиятле вакыйга булды. Экспозициянең тагы «Татарстан Республикасы Милли музее тупланмасында татарларның милли киеме» дип аталган проектның тупланмасы белән «Татарстанның мәдәният ресурс үзәге» ДБУ директоры Алсу Равил кызы Мифтахова шәхсән үзе таныштырды. Һәр кием, үзенең нәфис чигешләре, уникаль өлгесе һәм






Исегезгә төшерәбез, 8 февральдә Җиддәдә «Казань – ислам дөньясының мәдәни башкаласы» елының презентациясе булды. Аның ачылышы 14 майда «Россия – Ислам дөньясы: KazanForum» Халыкара икътисади форум кысаларында узачак.

Рөстәм Миңнеханов Ислам дөньясы оешмасының мәгариф, фән һәм мәдәният мәсьәләләре буенча генераль директоры белән очрашуда Тукай исемендәге Халыкара премияне гамәлгә куярга тәкъдим итте

бизәкләрендәге символ-тамгалары белән татар халкының осталыгы, зәвыгы, үзенчәлеге турында сөйли.

Рәссам-каллиграф, Россия Рәссамнар берлеге әгъзасы Гөлназ Исмәгыйлева үзенең нәзакәтле эшләр шәкелен тәкъдим итеп кенә калмады, ә татар рухи мәдәниятенә юл салучы булды. Ул кунакларны фәлсәфәгә корылган борынгы шәмаил сәнгате белән таныштырды.

«Тере мирас» күргәзмәсе карап хозурланудан гайре, актив катнашу мөмкинлеге дә бирде. Фестиваль кунакларына татар мәдәниятын эчтән таныту максатында төрле төстәге күн кисәкләреннән искитмәле бизәкләр хасил итүче мавыктыргыч уникаль техника – күн мозаикасы буенча осталык дәресләре оештырылды. Шул рәвешле һәр бормасы һәм чәчәге символик мәгънәгә ия булган милли бизәкләрнең серен чит мәмләкәттәгеләргә дә таныттык. Бергәләп хуш исләре аңкып торган милли ризыклар әзерләп татарның кунакчыллыгын күрсәттек. Татарстан стенды тарту көченә ия бер үзәккә әверелде. Тамырларыбызның, милли мирасыбызның үзенчәлеген саклаган хәлдә ничек итеп дөнья белән тере, заманча диалог алып баруыбызны ап-ачык итеп күрсәтә алдык. Әлеге проект Татарстан һәм Россиянең халыкара мәйданда позитив имиджын ныгытып, ышанычлы дуслык күперләре төзеп, уртак мәнфәгатьләр булдыруы – уңышлы мәдәни дипломатиянең ачык бер мисалы булып тора.

■ Әр-Риядта (Согуд Гарәбстаны) узган «ИННОПРОМ» халыкара сәнәгать күргәзмәсендә Татарстан Республикасы стенды тәкъдим ителде.

Экспозициянең үзәк өлешен республиканың мәдәниятенә һәм тарихына багышланган бүлек алып торды. Анда кунаклар «Казан – ислам дөньясының мәдәни башкаласы» елының программасы, рәссам-каллиграф Гөлназ Исмәгыйлеваның каллиграфик эшләре, Татарстанның тарихи мирасы белән таныште.

Күргәзмә эшендә Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Миңнеханов катнашты һәм «ИННОПРОМ. Согуд Гарәбстаны» пленар сессиясендә чыгыш ясады.

Форумда катнашучыларны һәм кунакларны Республиканың мәдәни потенциалы белән Татарстанның мәдәният министры Ирада Әюпова таныштырды.

■ Катар башкаласында Россия Мәдәният министрлыгы һәм Катар Дәүләтенең Мәдәният министрлыгы теләктәшлегендә Россия мәдәнияте көннәре узды. Чаралар «Дарб Әл-Саади» кластеры – Катар мәдәни мирасының иң мөһим мәдәни объектлары территориясендә узды. Илнең мәдәни мөмкинлекләрен күрсәтүче төбәкләр арасында Татарстан Республикасы да бар иде.

Россия Федерациясе делегациясен РФ мәдәният министры Ольга Любимова җитәкләде. Ул республика стендында тәкъдим ителгән экспозиция белән таныште. Татарстанның тарихи-мәдәни мирасы, шулай ук «Казан – ислам дөньясының мәдәни башкаласы» елы программасы белән кунакларны һәм Доха халкын Татарстан Республикасының мәдәният министры Ирада Әюпова таныштырды.

Махсус программа кысаларында Татарстан осталары анда катнашучыларга татарның уникаль һөнәрчелек сәнгатен таныт-ты. Тәкъдим ителгән техникалар арасында күн мозаикасы, туку, тырнак алмалау, каллиграфия һәм киез басу бар иде. Әлеге юнәлешләрнең күбесе Катарның традицион сәнгать төрләре белән



аваздаш диярга була. Аның шулай булуы халыкта аеруча кызыксыну уятты. Яшьләр өчен интерактив мәйданнар эшләде, анда булган һәркем татар бизәген рәсемгә төшерергә өйрәнде.

Россия мәдәнияте көннәрен ачу тантанасында Татарстан Республикасының Дәүләт җыр һәм бию ансамбле катнашты һәм тамашачыларга республиканың үзенчәлекле музыкаль мәдәниятен күрсәтте.

**ИСЕСКО Татарстан Республикасы Рәисенең Габдулла Тукай исемендәге Халыкара премиясен булдыру тәкъдимен уңай кабул итте**




**Фотолар Татарстан Республикасы Рәисе рәсми сайтыннан**

# ТАТАРНЫҢ ЭЛМӘ (ТАМБУР) ҖӨЕ: *гасырлар аша бүгенгәчә*



Гүзәл ВӘЛИЕВА-СӨЛӘЙМАНОВА,
*сәнгать фәннәре докторы, профессор*

**Чигү – татар хатын-кызлары арасында элек-электән иң популяр кул эшләренең берсе саналган. Басу-кыр, хуҗалык эшләреннән калган бөтен вакытларын, бар булган иҗади мөмкинлекләрен чигүгә юнәлткән алар. Кызлар кечкенәдән чигү серләрен өйрәнеп, үзләренә бирнә әзерләгән: булачак киявенә, аның әти-әнисенә бүләк; урын-җир, өй бизәү өчен кирәк-ярактан тыш Сабантуй сөлгесенә кадәр хәстәрләп куйган.**

Буыннан-буынга килгән гадәт буенча һәр йортта нинди дә булса кул эше тотканнар. Хәтта чигүчеләре белән дан тоткан авыллар да булган. Анда осталар үзләре өчен генә эшләү белән чикләнмәгән, сатуга да чыгарганнар. Өйдә заказ буенча эшләүче чигүчеләрнең тамбур җөйле һәм алтын белән башкарылган эшләнмәләре алыпсатарлар аша әллә кайларга – башкорт далаларына, Урта Азиягә, Себергә, Россиянең көнбатыш районнарына Новгород якларына кадәр барып җитә. Татарның чигүче осталары аша ул халыкларның сәнгатенә дә Казан татарларының орнаментларындагы күп кенә мотивлар, бизәкләр үтеп керә. Музейларның этнография тупланмаларындагы чигешләрнең күпчелеге XIX гасыр ахыры – XX гасыр башына карый. Музейларда XVIII гасыр уртасы һәм XIX гасырга караган аерым үрнәкләр дә сакланган.

Борынгы элмә-тамбур җөе техникасы йөз еллар дәвамында сакланып килә. Ул Россия Федерациясендәге барлык төрки халыкларның чигешләрендә дә очрый. Шуңа да карамастан ул бары тик татарларда гына өйдәге кул эше булырак кына түгел, ә профессиональ һөнәрчелек буларак үсеш ала. Элмә татар сәнгатенең милли үзенчәлекле төре булып тора, аны еш кына «татар чигүе» дип тә йөртәләр. Андый эшләрнең татар халкы яшәгән бөтен җирдә таралуы нәкь менә шуны дәлилли. Мисал өчен, «тапкырлап» чигүне рус чигүе дип атаганнар. Шәхсән үзем Кама аръягындагы татар авылларында узган экспедиция вакытында, тамбур җөе-элмәнең тагын бер атамасы – «чылбырлы чигү»гә тап булдым.

Элмә белән чигелгән сөлге башлары, урынҗир япмалары, чаршау, кашага, намазлык, ашъяулык, өстәл япмалары, бирнә букчасы, ләүхәләр (Коръән аятьләре чигелгән панно) бөтенләй яңача яңгыраш ала. Кием-салым элементларына килсәк, аның иң мөһим саналган урыннары төрле максатларны күздә тотып, әйтик тагын да нәфисрәк итү, яки саклану чарасы буларак (әйтик, күз тиюдән) чигелә. Чигешләр еш кына күкрәкчә, алъяпкыч, итәк-җиң очларын, бала итәкләрне, ир-атның күлмәк якаларын, туй өчен әзерләнгән аяк чолгауларын, баш киемнәрен (калфак, түбәтәй, такыя, яулык), бәрхет һәм күн аяк киемнәрен, бөти саклагыч янчыкларны яисә «хәситә дәгъвәт», хаситәләрне бизи. Кызлар сөйгәненә истәлеккә бирәчәк кульяулык чигешләренә аеруча зур әһәмият биргән. 1920 еллар ахырында кызыл байракларга латин хәрефләре белән язып ТАССР эмблемалары һәм яңа хөкүмәт символлары чигелгән.



**Сөлге үрнәге.
Элмә чигүе. Киҗе-мамык җепләр.
Саба Мәдәният йортында оештырылган элмә курсларына йөрүче яшь һөнәрче эше**

**Казан арты. Остаханә чигүчеләре.
1930 еллар.
Фото Татарстан Республикасы Милли музее тупланмасыннан**



Нигездә Казан арты – Арча, Әтнә, Дөбъяз, Саба, Суык-Су кебек эре үзәкләр һәм шул тирәдәге авыллар чигүчеләр белән дан тоткан. Касыйм, Пенза татарлары чигешләренең нәзакәтлелеге бигрәк тә хатын-кызларның баш киемнәре – тастарларда ачык чагыла. Казанда – Иске һәм Яңа Татар бистәләрендә аеруча «Казан сөлгесе» – туй сөлгеләре затлы бизәлеше белән аерылып тора.

Татар элмә чигешенә бизәкләрнең ирекле рәвештә урнашуы хас. Алдан ук ничә чәнчем кирәк булуын исәпләү дә, нәфис чылбырны кайсы якка борып җибәрү дә таләп ителми. Шуңа күрә дә элмәне чылбыр кебек берсе икенчесенә үрелеп баручы ирекле җөйләргә кертәләр. Энә тукыманың уң ягыннан эчке ягына чыга һәм энә очы белән уң яктагы элмәк уртасына чыгып чәнчисең. Тәҗрибәле чигүчеләр эшкә керешкәндә, кагыйдә буларак, җепнең очын төйнәмиләр, әмма аны ике тапкыр чәнчеп беркетеп куялар. Һәр чираттагы элмәк гади чылбыр кебек берсе эченнән икенчесе чыга. Бу иң киң таралган алым булып санала. Ул киергедә энә һәм ыргак ярдәмендә башкарыла. Ачык чылбыр рәвешендәге ярым элмәле өзек җөй бары тик энә белән чигелә торган элмә төрләренә керә. Татар чигешләрендә тамбур җөй берничә төргә бүленә: эре-эре атлатып чигелгәне нигездә элмә дип аталса, калын җепләр белән, вак-вак атлатып башкарылганы – «күперткән элмә», «үреп чигү» (Кама аръягы татарларында) була. Соңгысы еш кына бөтерелгән ефәктән булганга күрә кабарынкы булып тора. Әлеге ысул белән чиккәндә энә ике җеп арасыннан чыга.

**Намазлык. Элмә чигүе.**
**Ефәк, ефәк һәм киҗе-мамык җепләр. Казан татарлары.**
**XIX гасырның икенче яртысы.**
**Россия этнография музее**



Татар элмәсенең технологиясе үзенчәлеге аның төрле ысулларны куллануда. Бизәкнең контурын да һәм эчлеген дә элмә үзе тутыра. Мондый алымны тутырып чигү диләр. Элмә боҗралары арасына шома җеп салып, эчлекне еш кына нагыш (гладь) җөе белән дә башкарып чыгалар. Контурлар исә бер яки икеләтелгән чылбыр белән чигелергә мөмкин һәм бу элмә җөенә күперткәнлек бирә, рельефлылык өсти.

Эш өчен күпчелек киҗе-мамык һәм йон җепләр файдаланылган. Декоративлылыкны арттыру өчен металл җепләр өстәгәннәр. XIX гасыр ахырыннан сатуда булган һарус һәм мулине кулланыла башлый. Алар белән башлыча чәчәк мотивларының өслеген чиккәннәр. XIX гасырның икенче яртысына кадәр энә белән эшләгәннәр, соңрак элмә ыргаклары (чигеш энәсе, элмәк) эшне шактый тизләткән. Квадрат рәвешендәге зур – ярты метрга чаклы киерге (кайбер авылларда аны «чәкән» дип атыйлар) кебек махсус чигү җайланмалары файдаланганнар. Борынгы киерге үрнәкләрен Биектау төбәкне өйрәнү музее экспозициясендә, Арча районы Кушлавыч авылында Тукаевлар гаиләсе музей-йортында, Яңа Кырлайда, Яшел Үзән районы Олы Ачасыр авылындагы архитектура-этнография музей комплексында һәм башка урыннарда күрергә була.

***Борынгы элмә-тамбур җөе техникасы йөз еллар дәвамында сакланып килә. Ул Россия Федерациясендәге барлык төрки халыкларның чигешләрендә дә очрый. Шуңа да карамастан ул бары тик татарларда гына өйдәге кул эше буларак кына түгел, ә профессиональ һөнәрчелек буларак үсеш ала. Элмә татар сәнгатенең милли үзенчәлекле төре булып тора, аны еш кына «татар чигүе» дип тә йөртәләр.***



**Түгәрәк киергедәге тастымал. Элмә чигүе. Биектау районы Дөбъяз авыл мәктәбенең төбәкне өйрәнү музее**

**Хатын-кыз җиңсәләре. Элмә чигүе. Киҗе-мамык тукыма һәм җепләр. Казан татарлары. ТР Милли музее тупланмасындагы XX гасыр башына караган үрнәкнең реконструкциясе. Автор Л. Фәсхетдинова. 2000 еллар**



1870 елларда Европада элмә чигү машинасы барлыкка килү әлеге җөйнең күпләп таралуына сәбәп була. Ул хәтта шәһәрләрдә хәлле гаиләләрдә үскән татар кәләшләре бирнәсенең алыштыргысыз атрибутына әверелә. Шунлыктан XX гасыр башында элмә җөе шәһәр кешеләренә дә, шул ук вакытта авыл халкына да ят нәрсә булмый. Тамбур машинасының таралуы чигү сәнгатен һөнәрчелек тармагының бер төре буларак үсешенә, нәтиҗәдә элмә белән чигелгән әйберләрнең күпләп базарга чыгуына этәргеч бирә.

Татар авылларындагы чигешләрнең күбесе кулдан башкарылган. Гадәттә тукымага алдан төшерелгән сурәт буенча, ә тәҗрибәле осталар күчергеч итеп алган сурәттән карап кына да чиккәннәр. Композицияләрне, бизәкләрне иске өлгеләр – чигешләр өстенә яңа тукыма, яки кәгазь куеп күчергәннәр. Сурәт күренсен өчен тукыма өстен көмеш беләзек яки калак белән ышкыганнар. Аннан соң рәсемне графит, сабын, яки синиль карандаш белән көчәйткәннәр. XX гасырдан башлап, бу максатта тукыманың төсенә карап төсле копировка кәгазьләре файдаланалар; шулай ук үтә күренмәле кәгазьне беркетеп шуның өстеннән дә чигәләр. Бизәкнең үлчәмнәрен үзгәртер өчен аны тигез квадратларга бүлеп сызып чыгалар һәм кәгазь битенә күчерәләр. Һәр оста зәвыгына карап бизәккә үз детальләрен, төсләрен өсти.

Тасма, букет, челтәрле композицияләрдәге чәчәк-үсемлек бизәкләре – лалә, кыңгырау, күгәрчен күзе, мәк, канәфер, күкчәчәк, акбаш (ромашка), кашкарый, алтын чәчәк, дәлия, чалма чәчәк, роза кебек кыр, болын, бакча чәчәкләре, «төрек кыярлары», анарлар хас элмәле чигүгә. Шул ук вакытта кош, күбәләк, бал корты, этәч, күгәрченнәрнең стильләшкән мотивлары; Болгар һәм Алтын Урда бизәкләренә тиң тукранбаш, лалә, нилүфәр (лотос) чәчәкләренең үзгә вариантлары, үрмәгөл, йөрәк рәвешендәге яфраклы чәчәкләр, «гомер агачы» да очрый. Бик нык стильләшкән мотивлар исә туй сөлгеләренең бизәкләрендә пар кошлар, балыклар, жайдак атланган ике-башлы атлар рәвешендә еш очрый, бу борынгы татарларның дөньяга дуалистик карашларына барып тоташа. Чигешләр төсләр байлыгы белән аерылып тора (бер эштә генә дә 10-12 төс яраклашып килергә мөмкин). Зәңгәрсу, зәңгәр, пестә төсе (сыек яшел), яшел, алтын-сары, шәмәхә, куе алсу, кызыл, ак, төсләр бик популяр.



**Борынгы киерге.
XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы. Биектау төбәкне өйрәнү музее**

XX гасыр урталарында тамбур җөе сәнгать төре буларак әкренләп көнкүрештә юкка чыга. Шулай да ул халык арасында үзешчән сәнгать төре буларак яши, әмма әкренләп бизәкле композицияләр чигү осталыгы кимүгә бара. Осталар «Азат хатын», «Работница», «Крестьянка» кебек совет журналларында басылган чигү үрнәкләренә мөрәҗәгать итәләр. Аларда роза, канәфер, мәк кебек чәчәкләрне тапкырлап һәм нагыш ысулы







Йола сөлгесе. Элмә чигүе. Киҗе-мамык тукыма һәм җепләр, гарус (мамык тукыманың бер төре), челтәр, тасма. XIX гасыр ахыры. Н. И. Воробьев тупланмасыннан. ТР Милли музее

Йола сөлгесе. Элмә чигүе. Киндер, комач. Киҗе-мамык һәм йон җепләр. XX гасыр башы. Әлмәт районы Яңа Нәдер мәктәбенең этнография музее



«Раилә» – хатын-кызлар сумкасы. Кулдан чигелгән тамбур җөе. Чын бәрхет, күн, киҗе-мамык җепләр. Казандагы «SULTAN» студиясе остаханәсе. 2020 еллар



Янчык. Кулдан чигелгән тамбур җөе. Ясалма замша, киҗе-мамык җепләр. Казандагы «SULTAN» студиясе остаханәсе. 2020 еллар



Жакет. Кулдан чигелгән тамбур җөе. Җитен, киҗе-мамык җепләр. «MADINATATARKA» ателье-бутигы. Әлмәт шәһәре. 2020 еллар

***Татар чигешләрендә тамбур җөй берничә төргә бүленә: эре-эре атлатып чигелгәне нигездә элмә дип аталса, калын җепләр белән, вак-вак атлатып башкарылганы – «күперткән элмә», «үреп чигү» (Кама аръягы татарларында) була. Соңгысы еш кына бөтерелгән ефәктән булганга күрә кабарынкы булып тора.***

белән тоташ чигү үрнәкләре пропагандалана. Шул рәвешле татарларның бай төсләр гаммасын үзенә туплаган элмә җөйле чигешләре урынына нәфислек ягыннан түбән дәрәҗәдә башкарылган эшләнмәләр өстенлек ала һәм бу чигүне сәнгать төре буларак юкка да чыгара.

Шөкер, соңгы берничә дистә еллар дәвамында әлеге юнәлеш мәдәниятебезнең җете бер күренеше буларак, элмә җөен югары сәнгать дәрәҗәсендә үзләштергән профессиональ рәссамнар һәм осталар иҗатында колач җәя. 1990 елларда «Туран Арт» ҖЧҖ остаханәләрендә элмә, тутырып чигү һәм ука белән чигүле эшләнмәләр җитештерү җайга салына. Уникаль үрнәкләр машина белән дә, кулдан да эшләнә. Җитештерү торгызыла, ассортимент киңәя (костюмнар, йола сөлгеләре, декоратив пәрдә-чаршаулар, намазлыклар, диван мендәрләре, скәтер, япма, изү, камилләштереп тукымадан эшләнгән хәситә, алъяпкыч, сумка һ.б.). Рәссамнар һәм халык осталары тарафыннан «Казан сөлгесе»нең тупланмасы булдырылды. Аларның бизәкләре борынгы үрнәкләрдәгечә дә, дизайнерлар тарафыннан яңартылган вариантларда да эшләнә. Бу шул ук вакытта диван мендәрләре тупланмасына да кагыла. Алардагы бизәкләр элеккеге чигү үрнәкләреннән күчереп алып төс, композиция ягыннан яңа төсмерләр белән баетылган. Чигүле эшләнмәләрнең эскизларын Л. Чубукова, С. Гарбузова, Е. Гыймранова һ.б. дизайнерлар иҗат итә. XX гасырның икенче яртысында танылган чигүчеләр һәм шул ук вакытта үз эшләренең дизайнерлары дип М. Бикбулатова, С. Кузьминых, Р. Фәйзуллина, Л. Фәсхетдинова, С. Гарбузова, А. Липина, А. Стоянова һәм башкаларның исемнәрен атыйбыз. Аларның эшләрен югары сәнгать әсәрләренә кертергә мөмкин. Чигүле эшләнмәләр күпләп тә, һәм шул ук вакытта уникаль күргәзмә үрнәге буларак та җитештерелә. Үзешчән осталар үзләре файдаланыр өчен генә түгел сатуга да эшлиләр. Эшләнмәләрне еш кына күргәзмә сатуларда, төрле презентацияләрдә тәкъдим итәләр. Чигүчеләр үзләренең күзаллауларына, тәҗрибәләренә таянып оригиналь әсәрләр эшләү белән беррәттән гаилә, музей ядкәрләре булган борынгы чигешләрне дә күчереп ясыйлар. Еш кына күчерелмә һәм борынгы эшләнмәләрнең прототиплары һәм бизәкне төрләндереп, үзгәртеп стильләштерү, кагыйдә буларак, заманча сәнгать зәвыгына туры килә. Кулдан чигелгән тамбур җөе бүген традицион ука белән чигү техникасы, нагыш җөе, сәйлән, пайетка һәм башка бизәгеч материаллар белән ярашучы җете бер күренеш буларак күз алдына килә.

Чигешле эшләнмәләр җитештерүне җайга салучы фирмалар барлыкка килү әлеге тармак үсешенә чын-чынлап куәт өсти. Бүләк һәм сувенир эшләнмәләр сыйфатында аларны аз-азлап җитештерәләр. Казанда һәм Яр Чаллыдагы авторларның остаханәләрендә (Х. Гареева, Л. Галимова, А. Фаздалова, Ә. Нурхәмәтова, Е. Конякина, А. Гыймадеева, А. Рамазанова, Р. Полосина, Э. Фәткуллина һ.б.) заказ буенча һәм сувенирлар сыйфатында милли бизәкле чигешләр иҗат ителә. Шәһәр тибындагы Байлар Сабасы бистәсендә Фәрит һәм Лилия Вафиннарның «Саба мендәре» дигән гаилә остаханәсе эшли. Эшчәнлекнең төп юнәлеше – машинада чигү һәм аппликация. Биредә намазлыклар, мендәрләр, мендәр тышлыклары, күн (ясалма күн) сумкалар, көндәлекләр эшлиләр. Остаханәдә Саба районы мәктәпләре укучылары өчен осталык дәресләре дә уздырыла.

Татарстан Республикасының чигеп эшләнгән картасы кебек артефактта да тамбур җөе үзенең матурлыгы белән җәлеп итә һәм әлеге сәнгатьнең милли үзенчәлеген ачып бирә. Ул Татарстан Республикасы Милли музеенда саклана.

# XVII–XVIII йөз татар риваятьләрендә фольклор *һәм тарихи хәтер бәйләнеше*

Лилия МӨХӘММӘТҖАНОВА,
*филология фәннәре докторы, доцент,*
*Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының баш фәнни хезмәткәре*



**Тарихи хәтер – җәмгыятьтә булган мөһим вакыйгалар, шәхесләр, социаль тәҗрибә, мәдәни традицияләр турында белемнәрне саклау һәм тапшыру процессы ул. Билгеле дәрәҗәдә аерым бер халыкның килеп чыгышын, тарихын, аның менталь үзенчәлекләрен чагылдыруы сәбәпле, тарихи хәтер милли төсмергә ия, бигрәк тә элгәрге этапларда бер халыкның тарихи хәтере икенчесенекеннән күпкә үзгә була. Тарихи хәтер халкыбызның зур сынауларда катнашуы, җиңеп чыгуы яисә җиңелүе, рухи һәм матди мирасны, тарихи хәтернең компонентлары булган милли телне һәм традицияләрне, шулай ук мәдәни казанышларны саклауда чагылыш таба; милләтнең үзбилгеләнүен формалаштыру өчен үзе бер мөһим механизмны тәшкил итә.**

## ТАРИХИ ХӘТЕР ҺӘМ РИВАЯТЬЛӘР

XVII–XVIII йөзләргә бәйле татар риваятьләрендә сакланган тарихи хәтерне барлау темасын алга чыгаруның сәбәбе шунда: әлеге гасырлар – татарларның социаль, икътисади һәм мәдәни тормышы бик нык үзгәрешләр кичергән, татар җәмгыяте катлаулы вакыйгалар белән тулы чор. Шуңа да бу вакыт аралыгына караган риваятьләрдә тарихи хәтер темасы татар халкының үткәнен, менталитетын, мәдәни мирасын өйрәнү өчен мөһим бер аспект булып тора. Халыкта катлаулы вакыйгалар, реаль шәхесләр, күренекле авыл һәм шәһәрләр белән бәйле сюжетлар иҗат итү традициясе һәрвакыт яшәгән. Узган заманнарда чынбарлыкта булган хәлләр турында сөйләнә килгән кыска сюжетлы эпик хикәяләр фольклористикада риваять жанры исеме астына берләшә.

Халык тормышының барлык якларын да колачлый торган риваятьләрнең исә тематикасы шактый киң, эчтәлеге бай. XVII–XVIII гасырларга караган риваятьләр асылда XVI йөздән татарларның социаль-иҗтимагый тормышында әледән-әле булып торган үзгәреш-хәлләрнең кайтавазы буларак яңгырый. Моңа кадәр күләмле эпос-дастан буларак мәгълүм кайбер сюжетлар да, жанр чикләрен җуеп, бу чорда риваять жанрында урын тапкан. Формалашып җитүе XVII йөзләргә карый дип уйланылган риваятьләрдән безнең көннәргә Иван IV чорында ук алып барыла башлаган көчләп чукындыру һәм яулап алу-буйсындыру сәясәтенең дәвамы һәм аның нәтиҗәләренә, чорның кыю һәм тапкыр кешеләренә, крестьян сугышлары вакыйгаларына, күренекле мәгърифәтче татарларга һәм халкыбыз төпләнеп яши торган атаклы төбәкләргә яисә авылларга багышланган ядкәрләр килеп җиткән.

## «ПАДИШАДАН УЗЫП ЗАКОН ЧЫГАРА АЛАСЫҢМЫ?..»

Рус дәүләте составындагы татарлар яңа тәртипләрне, милли һәм конфессиональ кысрыклауны авыр кабул иткәннәр. «Ишембай баба һәм аның уллары» [Татар халык иҗаты, б. 76]* дигән риваятьнең нигезендә, мәсәлән, Казан яулангannан соң рус дәүләтенең Казаннан көнчыгышка таба территорияләрне әкренләп үз кулына төшерү вакыйгалары ята. Сәяси буталышлар нәтиҗәсендә «Болгардан чыккан Ишембай баба»ның уллары үзара ызгышалар-талашалар, шуңа бәйле «Идел буйларыннан алып Урал тауларына чаклы булган» иксез-чиксез биләмәләр рус патшасы кулына төшә. «Яңа бистә» (б. 73) дигән исем белән мәгълүм риваятьне дә шушы ук төркемгә кертергә мөмкин. Тарихтан билгеле булганча, 1774 елның 1 сентябрендә Казан губернаторы итеп билгеләнгән князь Платон Мещерский Казанда Пугачев баш күтәрүе калдырган дулкынлануларны тәмам бетерү сәясәте алып бара, Пугачев ярларында активлык күрсәткән татарларны шәһәрдән читкә күчертә. Риваятьтә Мещерский «Каратун Ычтапан улы кенәз Мещерский» исеме белән телгә алына, XVIII йөз уртасында татарларны Иске Бистәдән Яңа Бистәгә күчереп утырту тарихы яктыртыла. «Дауд бабай» (б. 73), «Ибраһим карт» (б. 73), «Хәйләсен тапкан» (б. 73-74) дигән исемнәр белән сакланган риваятьләрдә исә көчләп чукындыруның икенче дулкыны вакыйгаларына бәйле татарларның дин алмаштырудан котылу тарихы бәян ителә. Аларда мөселман татарларның исламга тугрылыгы, курку белмәс батыр булуы белән бергә рус патшасының гаделлегенә ышанырга омтылышы да чагылыш таба, күрше чуваш халкының электән татарча яхшы белүләренә аңлатма бирелә һ.б. Әйтик, «Ибраһим карт» риваятендә мөселман кешесе чукындыру максаты белән килгәннәргә бик нык каршы тора, «Син падишадан узып закон чыгара аласыңмы?» (б. 73), дип, исправникның йөзенә төкерә, нәтиҗәдә Ибраһим картны Себер җибәрәләр.

## СЕБЕР ТАРИХЫ ХАКЫНДА ТАТАР РИВАЯТЬЛӘРЕ НИ СӨЙЛИ?

Янә бер төркем – Себер җирендәге тарихи вакыйгалар һәм алар калдырган нәтиҗәләр турында сөйли торган риваятьләр. Билгеле булганча, Себер ханлыгының рус дәүләте тарафыннан яулануы 1582–1598 елларга туры килә. Татар халык иҗатында әлеге һ.б. тарихи вакыйгаларга багышланган риваятьләрнең тууы һәм XVII йөзләрдән үк халыкта таралуы гаять табигый. Ермак, Күчем хан, себер татарлары һәм алар кылган батырлыклар һәм Себер территориясендә барган башка тарихи хәлләр «Әхмәтгәрәй хан», «Бараба халкы», «Кара калмак», «Күчем хан», «Барабаларның Тайчин баһадир белән көрәше», «Барабалар патша янында», «Касмак батыр» кебек тарихи риваятьләрдә җирле халык авызыннан тасвир ителә.

Шунысы игътибарга лаек, бу чорга хас югарыда телгә алынган тематик төркем риваятьләрендә дә, башка темага багышланган истәлекләрдә дә халык иҗатының эпик жанрларында элек-электән кулланыла килгән традицион мотивлар чагылыш таба. Әйтик, Казан ханлыгын

* Алга таба бу җыентыкта дөнья күргән текстларның исеме янында бит саны күрсәтелә бара.

яулап алу вакыйгалары хакындагы риваятьләрдә популярлык казанган, борынгы төрки дәвердән килә торган «ханнан үгез тиресе кадәр җир сорау» мотивы себер татарларыннан язып алынган һәм Себер ханлыгын яулау вакыйгаларына багышланган тарихи риваятьләрдә дә еш очрый. Бу чор риваятьләрендә дошман ягының көч белән генә түгел, хәйлә һәм мәкер белән дә алдыруы, ә җирле халыктан чыккан батырның исә дошманына каршы, чын каһарманнарга хас булганча, гаделлек белән көрәшүе, үз җиренә хөрмәт белән каравы һәм тугрылык саклавы шулай ук – татар халык иҗатының борынгыдан килә торган эпик традицияләре дәвамы. Шул ук вакытта себер татарларыннан язып алынган төркемдә, бердәмлек һәм ныклы оешканлыкның булмавы һ.б. сәбәпле, Себердә яшәүче җирле татарларның рус дәүләтенә үз ирекләре белән кушылу мәсьәләсе дә чагыла («Барабаларның Тайчин баһадир белән көрәше», «Барабалар патша янында», «Күчем хан» һ.б.). Әмма мондый риваятьләрдә, әйтик, Бохарадан ярдәм сорауның татарларның калмык, казакъ яуларына каршы торырга үз көчләре генә җитмәгәнлектән, ягъни ирексездән булуы хакында да сөйләнә, бу адымның хупланмавы сизелеп тора, дошман ягының алдап җиңүе мотивы күзәтелә.

## ТАРИХИ РИВАЯТЬЛӘРДӘ АКСАК КАРАТУН

XVIII йөз риваятьләрендә мөселман татарларны көчләп чукындыру темасы дәвам итә, аларның сюжеты шул заманда булган тарихи вакыйгаларга барып тоташа. «Аксак Каратун» (б. 70-72) исеме белән мәгълүм риваятьтә, мәсәлән, 1738–1755 елларда Казан архиепископы булып торган, 1740 елда ачылган «Контора новокрещных дел» оешмасы вәкиле Лука Канашевичның татарларны көчләп чукындыру юнәлешендә башкарган кансыз кыланмышлары һәм комсыз гамәлләре турында сүз бара. Билгеле булганча, халык телендә Лука Канашевичны Аксак Каратун дип атап йөрткәннәр. Риваять мөселманнарны су буена куып төшереп, карышучыларны камчы белән суктырып христиан ясаулары турында сөйли. 1742–1744 еллар эчендә Казан губернасында мәчетләр күпләп юкка чыгарыла. Шушындый кыргый эшләрнең башында торган Аксак Каратунны халык үзенең риваятьләрендә булса да җәзага тарта. Аксак Каратун «ертык киемнәрдә монастырь ишегалдында йөри икән, башы йөзе белән артка караган» рәвешендә сурәтләнә, янә бер вариант татарларга карата яманлыклар кылган бу затның язмышы турында түбәндәге хәбәрне җиткерә: «Аксак Каратунны, төшереп, Зөя монастырена япканнар. Шунда күп гомер сөреп, ахырында йөзе тискәре әйләнеп вафат булмыштыр» (б. 308).

«Югалган авыл» (б. 75) риваятен дә бу чорның югарыда аталган темасы, ягъни көчләп чукындыру сәясәтенә мөнәсәбәтле истәлек дип бәяләргә мөмкин. 1713 һәм 1715 елларда Петр I мөселман морзаларын чукындыру турындагы указлар чыгара. Шушы тарихи вакыйгаларга бәйле, риваятьтә сүз XVIII гасыр башында миссионерларның Рязань өлкәсе татар авылларына килеп, андагы мөселман халкын чукындырып йөрүләре турында бара. Биредәге Ермишин районына Богослов фамилияле бер миссионер үзенең хәрби отряды белән килгәч, алданрак христианлыкка күчкән берничә мишәр моңа Әҗе исеме белән билгеле авылны күрсәтергә тиеш була. Әҗе авылы тау астындагы авыл, имеш. Юл күрсәтүчеләр богословны үз артларыннан ияртеп алып баралар, карасалар, түбәнлектә урнашкан авылны диңгез шикелле зур ташкын суы чолгап алган, якын килерлек түгел икән. Миссионер, үзен бирегә алып килгән чукынган татарларны суга батырып үтерергә теләүдә гаепли, мине алдадыгыз, дип, аларның башларын кистерә. Үзе, отрядын алып, кирегә борыла. Әҗе авылы шулай чукындырылудан котылып кала. Риваять фольклорга хас контаминациядән азат түгел, биредә «Петр I 1682 елда татар алпавытлары һәм морзалары егерме биш көн эчендә чукынмасалар, аларның бөтен крестьяннары вә күчми торган милекләре мөсадәрә кылыныр *(ягъни кулга алыныр, конфискацияләнер. – Л.М.)* дигән указ чыгара» диелә. Тарихи даталарның буталып бирелүе – фольклорга хас күренеш.

Шушы ук риваятьтә («Югалган авыл») җирләреннән һәм крестьяннарыннан колак кагу янаган татар морзалары Янгалычев, Килдишев, Маисов, Мирлин, Кудашев, Кугушев, Маманов, Шәкүров, Балашовлар һ.б. бик күп татар морзаларының чукындырылу факты искә алына.



Гавриил Горелов «Пугачев Казанда хөкем итә». 1925

Тарихтан билгеле булганча, көчләп чукындыруның XVII йөздән үк башланган һәм XVIII йөзнең беренче яртысына тагын да көчәйгән икенче дулкыны татар рухи дөньясында, чыннан да, үз эзен тирән калдырган. Телгә алынган исемнәрнең XVII гасыр башыннан алып Россия үсешенә зур йогынты ясаган татар чыгышлы югары катлам вәкилләре булуы мәгълүм. Үз чорында ук бу шәхесләрнең исемнәре риваятьләрдә сакланып калу фольклор истәлекләренең тарихи әһәмиятен бермә-бер арттыра.

## МИЛЛИ-СӘЯСИ КӨРӘШ ТЕМАСЫҺӘМ ЧОРНЫҢ КҮРЕНЕКЛЕ ШӘХЕСЛӘРЕ ТУРЫНДА РИВАЯТЬЛӘР

Бу чорга хас риваятьләр арасында аерым бер төркемдә – качкынлык вакыйгаларын яктырткан әсәрләр. Качкыннар – татар халкы тарихының билгеле бер дәверендә милли һәм социаль азатлык өчен көрәшү картинасын тулыландыра торган образлар. Качкыннар язмышы турында татар халык иҗатында риваятьләр дә, тарихи җырлар да шактый күп иҗат ителгән, хәтта кайвакыт халык бер үк качкынга багышланган бәет тә, тарихи җыр да, риваять тә чыгарган. XVII–XVIII йөзләрдән билгеле, качкыннарга багышланган тарихи риваятьләр дип Казан губернасы Тәтеш өязендә (1781–1920) солдатта егерме биш ел хезмәт итүдән качкан Хисами исемле солдат турындагы «Хисами качкын белән сотник», комсыз байларны талап көн күрүче Бәкернең галәмәтләренә багышланган «Бәкер» (б. 96), патша чиновникларын, байларны талап җыйган барлык малын кыерсытылган халыкка тарату белән шөгыльләнгән кыю качкын турындагы «Баязит урманы» (б. 92), 1798–1865 елларда хәзерге Башкортстан территориясенең кантоннарга бүленгән чорында халык чуалышларында могҗиза белән исән калып, үсеп җиткәч патша чиновниклары асарга хөкем итеп тә, атасы җайлап янә исән калган Нугайбәк исемле кантон башлыгы «Нугайбәк кантун» (б. 90) һ.б. ядкәрләрне күрсәтергә мөмкин.

Татар риваятьләре, милли-сәяси күтәрелешнең пассив формасы булган качкыннар темасын популярлашу белән бергә, аеруча XVIII йөз ахырларында халыкта актив күтәрелешләрне дә сурәтли. Крестьян хәрәкәтләре белән бәйле риваятьләрнең күбесе тарихтан мәгълүм Емельян Пугачев, Салават Юлай, Бәхтияр Канкай турында хәбәрләр җиткерә. Әлеге темага караган

истәлекләрнең халыкта әле бүгенгә кадәр саклanып калуы, XXI гасыр башында да бу вакыйгалар турында тарихи риваятьләрнең тере сөйләмдә яшәве игътибарга лаек. «Пугачев», «Пугачев отрядлары», «Пугачевчылар Казанда», «Салават штабында», «Юлай карагы» – әнә шушы тематик төркемгә керә торган фольклор истәлекләре. Героик дастаннардан – «Идегәй», «Чура батыр»-лардан килә торган традициядәгечә, халык үз җирендәге реаль шәхестән герой ясарга омтылган, үз батырын мактаган, аның турында сөйләгән. Пугачев восстаниесе һәм анда катнашкан татарлар батырлыгын халыкның бүген дә онытмавы каһарманлык турындагы эпос-дастаннардан килә торган «халык батыры» темасының бөтенләй бетеп бетмәве дип әйтергә мөмкин.

Татар мәгърифәтчеләре һәм күренекле шәхесләр турында сөйли торган риваятьләрне дә бу чор риваятьләренең аерым төркеме дип күрсәтәбез. Габделҗаббар Кандалыйга багышланган «Ишан рухына» (б. 104), «Габделҗаббар ишан» (б. 104) дигән риваятьләр, мәсәлән. Мөселманнарга мәчет салдырырга рөхсәт биргән Екатеринага багышланган «Әби патша» (б. 64), үз заманында Казан халкы арасында мәшһүр һәм могътәбәр кеше буларак танылган Ишбулат мулла һәм аның нәселе турында «Ишбулат мулла нәселе» (б. 69) һ.б. риваятьләр шулай ук әлеге төркемне тулыландыра.

## ХАЛЫК ИҖАТЫ ҺӘМ ТАРИХ ӨЗЛЕКСЕЗ БӘЙЛӘНЕШТӘ

XVII–XVIII йөзләр белән бәйләп карар өчен нигезе булган риваятьләр кайсы гына темага карасалар да, аларда коткаручы батырның әйләнеп кайтуы, табылдык бала, яуга каршы чыккан каһарманның ялгыз батырлыгы, геройның гайре табигый сыйфатларга ия булуы кебек халыкара эпик сюжет-мотивларны тотып алу кыенлык тудырмый. Бу чорга хас риваятьләрнең барысында да тарихи чынбарлык вакыйгалары белән бергә бик борынгыдан бирле халык иҗатында күзәтелә торган мотивларның еш очравы – фольклорда традиционлык, дәвамчанлык һәм күчемлелек кагыйдәләренә, тарихи хәтер сакланышына һәм чагылышына барып тоташа торган закончалыклы күренеш.

Билгеле бер иҗтимагый шартларда барлыкка килеп, буыннан буынга күчеп сакланган, замана вакыйгаларының эпик картинасын тудырган тарихи риваятьләр арасында XVII–XVIII йөзләргә нисбәтлеләренең, аеруча татар дөньясында XVIII йөз вакыйгаларын чагылдырганнарының тарихи җәһәттән дә, авыз-сүз сәнгате буларак та әһәмияте бар. Ил-көн өчен аеруча мөһим саналган вакыйгалар арасында бүгенге көнгә фәкать халык иҗаты гына хәбәр итә торган тарихи фактлар да очрап куярга мөмкин. Әсәрләрнең эчтәлеге тарихны киң колачлый, компактлы булуы белән игътибарны җәлеп итә. Барлыкка килүе, таралуы, яшәве XVII–XVIII гасырларга туры килә дип билгеләнгән риваятьләрдә халык күңеленә тирән уелган реаль хәлләргә киң һәм тирән гомумиләштерүләр ясала. Халык шигъриятенең гүзәл казанышы булган бу әсәрләрнең стилендә, эчтәлегендә, сюжет һәм мотивларында фольклорда борынгы заманнардан ук килә торган традицияләр белән бергә, шул чор сулышы сизелә. Чыганакларына килсәк, бу чор ядкәрләре телдән-телгә күчеп кенә түгел, язмалар аша да нәкъ менә шушы гасырлардан алып яхшырак сакланып калганнар, шулай ук халык күңелен тетрәткән тарихи вакыйгаларның аз булмавы да фольклор үрнәкләренең күпләп тууын тәэмин иткән. Тарихи чорга хас иҗтимагый-сәяси шартларга бәйле, XVII–XVIII гасырларда фольклор әсәрләренең төп асылын, чор вакыйгаларын тасвирлау белән бергә, баш бирмәү теләге, рухи һәм милли кысрыклаудан котылу идеясе билгели, әсәрләрдә халыкның тарихи үткәне дә, аның эчке дөньясы, рухи кичерешләре дә алгы планга чыга. Кешенең үз халкы, иле тарихына катнашы булуын тоемлавына, үткәннәргә карата кичерешләренә нигезләнгән риваятьләр фольклор әсәре генә түгел, тарихи хәтер буларак та кыйммәт. Тарихи хәтер һәм халык иҗаты әсәрләре, бу очракта риваятьләр, һәрдаим үзара бәйләнештә.

**Чыганаклар:**
1. Татар халык иҗаты: Риваятьләр һәм легендалар / ТФА Г. Ибраһимов ис. Тел, әдәбият һәм тарих институты. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1987. – 368 б.

**2026 ЕЛ ТАТАРСТАНДА ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ЕЛЫ ДИП ИГЪЛАН ИТЕЛДЕ**

# ТУКАЙ КИТАПЛАРЫ
## *нәшер ителү тарихыннан (1907-1914 еллар)*

Гүзәл ТӨХВӘТОВА,
*филология фәннәре кандидаты,*
*Габдулла Тукай әдәби музее мөдире,*
*КФУның Гомуми тел белеме һәм*
*тюркология кафедрасы доценты*




**XX гасыр башында Габдулла Тукай китапларының басылып чыгу тарихыннан материаллар, шулай ук андагы иллюстрацияләр, аларны сату һәм реклама текстлары.**

Татар китапларының басылып чыгу тарихында бөек шагыйребез Габдулла Тукайның китаплары мөһим урынны алып тора. Шигырьләрен халык яратып укый, аның әсәрләреннән үзенә җан ризыгы таба. Татар китаплары арасында беренчеләрдән булып Г. Тукай китаплары матур бизәкле рәсемнәр, иллюстрацияләр белән чыга башлый. Әлеге китапларга иллюстрацияләр юктан гына килеп кермәгән: Тукай эзләнгән, яңалыкка омтылган. Мәсәлән, шагыйрь рус журналларын, балалар өчен махсус чыгарылган басмаларны укып барырга тырышкан, хәтта чит ил рәссамнарының эшләрен дә өйрәнгән, алардан тәҗрибә тупларга омтылган.

Бүгенге көндә Г. Тукайның үзе исән вакытында нәшер ителгән китаплары, нигездә, Татарстан Республикасының Милли музее фондында, КФУның Н.И. Лобачевский исемендәге фәнни китапханәсендә, Татарстан Республикасының Милли архивында, Татарстан Республикасының Милли китапханәсендә саклана. Бу темага кагылышлы материаллар ТР Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәгендә бар. Санкт-Петербургтагы Россиянең Милли китапханәсендә шагыйрьнең төрле елларда нәшер ителгән басмаларын табарга мөмкин. Китапларның басылып чыгу даталары матбугат эшләре буенча Казан вакытлы комитетының дөньяга чыккан барлык басма китапларның теркәү дәфтәрендә билгеләнә.

Г. Тукайның китаплары нәшер ителү турында беренче мәгълүматлар шагыйрьнең 1907 елның 9 нчы июнендә Җаектан Казанга Шәрәфләр матбагасына язган ачык хатында теркәлгән: «Хөрмәтле Гыйльметдин Шәрәф әфәнде! Тарафыңызга, заказной бандероль уларак, «Әшгаре мәҗмуга»мны йибәрдем. ...Үзеңез дикъкатьләп карап чыгыңыз да, нәшер итәргә разый булсаңыз, миңа тизлек берлә 50 тәнкә акча йибәреңез».

Нәтиҗәдә «Шигырьләр көтепханәсе»ндән өченче дәфтәр буларак 1907 елның 15нче ноябрендә 4 000 данә тираж белән «Шәрәф» матбагасында «Габдулла Тукаев шигырьләре» китабы




**Тукаев Г. «Җуаныч». «Мәктәп мөкяфәте»ннән беренче китап. Казан, 1908**



**Г. Тукайның «Су анасы» поэмасына иллюстрация. («Җуаныч», 1908)**

**Татар китаплары арасында беренчеләрдән булып Г. Тукай китаплары матур бизәкле рәсемнәр, иллюстрацияләр белән чыга башлый. Әлеге китапларга иллюстрацияләр юктан гына килеп кермәгән: Тукай эзләнгән, яңалыкка омтылган.**

нәшер ителә. Бу вакытта инде Габдулла Тукай Казанда яши, ләкин җыентыкка кергән шигырьләрнең күбесе Җаекта язылган: «Шүрәле», «Пар ат», «Бишектәге бала», «Шиллердан» һ.б. Китап басылып чыгуга ук «Әлислах» газетасында игълан бирелә: «Шигырьләр көтепханәсе»ндән 3нче дәфтәр «Габдулла Тукаев шигырьләре» бу көннәрдә Шәрәф матбагасында гүзәл суратта басылып чыкты. Бәһасе 12 тиен. Почта илә 14 тиен. Һәр йирнең мәшһүр китапчыларында сатыла. Наширләренә адрес: Казань, Типография Шараф» («Әлислах» газетасы, 8 сан, 1907 ел, 26 ноябрь).

Шагыйрьнең икенче китабы – «Габдулла Тукаев шигырьләре» («Шигырьләр көтепханәсе»ндән 4нче дәфтәр») 1907 елның ахырында чыга, ләкин тышлыгында 1908 дип күрсәтелгән. 1911 елда Казан губернасы жандарм идарәсе, Матбугат эшләре буенча Казан вакытлы комитеты тарафыннан бу китапка арест салу мәсьәләсе күтәрелә, аерым алганда «Ислахчыларга», «Китмибез», «Иттифакъ хакында», «Хөррият хакында», «Тавыш» хакында», «Мәдрәсәдән чыккан шәкертләр ни диләр» шигырьләре тикшерелә.

Алга таба Габдулла Тукайның «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш» әсәре аерым китап булып басылып чыга. Ул да шулай ук «Шигырьләр көтепханәсе» циклына кертелә. Китап Харитонов лито-типографиясендә 1908 елның 22 октябрьдә



Г. Тукайның «Алтын әтәч» әсәренә иллюстрация

5 000 данә тираж белән һәм аннан соң, озак та үтми, бу китап сатылып беткәч, ел ахырында ук тагын бер кат 5 000 данә тираж белән нәшер ителә. Г. Тукайның «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш» китабы «Әлислах» газетасының 48, 49, 50, 51, 52нче саннарында рекламалана.

1908 елда Г. Тукайның беренче иллюстрацияле китабы – «Җуаныч» («Мәктәп мөкяфәте»ндән беренче китап) нәшер ителә. «Әле бу арада тагы бер зур гына шигырь китабы яздым. Монысы, һәртөрле матур буяулы сурәтләр илә зиннәтләнеп, балаларга бүләк өчен язылды», – дип билгели Г. Тукай апасы Газизә Госмановага язган хатында. Бүгенге көндә китапның ике төрле варианты саклана. Мәсәлән, Казанда китапханә, архивтагы экземплярларда рәсемнәр юк, ә Россия милли китапханәсендә бу китапның рәсемле вариантын күрергә мөмкин. Рәсемнәрнең басмага кертелү-кертелмәвенә, кәгазьнең һәм тышлыкның сыйфатына карап нәшер ителүе – XX гасыр башында Тукай китапларының һәрбер кешегә, һәрбер укучыга барып җитү максатыннан уйлап табылган алым. Китапка төсле рәсемле кушымталар кертелмәсә, мондый китапны арзанрак бәядән сатып алырга мөмкин булган. Димәк, һәркем үзенең финанс мөмкинлекләренә туры килгән вариантта баласына Тукай әкиятләрен алып бүләк итә алган.

«Җуаныч» җыентыгының тышлыгында төсле итеп борынгы рус сәнгате стилендә грифоннар, драконнар белән эшләнгән орнаменталь рама урнаштырылган. Китапка «Таз» һәм «Су анасы» әсәрләренә ясалган төсле рәсемнәр кертелгән. Кызганыч, бүгенге көндә аларның рәссамнары билгесез.


1908 елда Габдулла Тукайның «Алтын әтәч» әсәре аерым китап булып басылып чыга (тышлыгында 1909 ел дип күрсәтелгән). Беренче басма – 5 000 данә тираж белән, һәм, озак та тормый, 1909 елның февраль аенда ук икенче басмасы 6 000 данә тираж белән дөнья күрә. Сәнгать белгечләре тарафыннан китапның сәнгатьчә бизәлеше югары бәяләнә. Китапка өч төсле рәсем кертелә. Рәсемнәрнең берсе А.С. Пушкинның 1888 елда нәшер ителгән «Алтын әтәч турында әкият» китабыннан алынган, аклы-каралы варианттан төсле форматка үзгәртелгән.

Г. Тукайның «Әдәбият» җыентыгы («Шигырьләр көтепханәсе»ндән 10нчы дәфтәр) 1909 елда басыла. Бу җыентыкта беренче тапкыр шагыйрьнең фотосурәте нәшер ителә. Соңыннан бу фотосурәт турында вакытлы матбугатта «Габдулла Тукаевның матбугатка чыккан беренче рәсеме» дип язып чыгачаклар. Әлеге рәсемдә шагыйрь бүгенге көндә Г. Тукай әдәби музеенда саклана торган түбәтәендә сурәтләнгән. Замандашлары искә алганча, аны шагыйрьгә 1908 елда яңа җыентык әзерләгәндә С.И. Иванов фотоостаханәсендә нәшир Гыйльметдин Шәрәф бүләк иткән була.

Әлеге фотосурәт Тукайның «Исемдә калганнар» (1909) китабына да кертелә. Ләкин шуның әйтергә кирәк, бу китапның музейда саклана торган басмасында фотография юк, ә Лобачевский исемендәге фәнни китапханәдә саклана торган экземплярында Тукайның фотосурәте урнаштырылган.

Балалар өчен аклы-каралы һәм төсле рәсемнәр белән бизәлгән «Күңелле сәхифәләр» китабы 1910 елда нәшер ишетелә. Ул ике төрле бәя белән сатыла. Аның кыйммәтрәк вариантына «Безнең гаилә» шигыренә махсус әлеге җыентык өчен ясалган иллюстрация кертелә. Галимә О. Улемнова үрнәк итеп М.Я. Чемберс-Белебинаның «Живое слово» китабында басылган рәсем алынуын искәртә. Рәссам анда шул ук композицияне файдаланган, фәкать катнашучылар санын, татар көнкүреше үзенчәлекләрен истә тотып, киемнәрен генә үзгәрткән. Рәсемнең әзерләнүе турында мөгаллим, дәреслекләр авторы, полиграфия эшлеклесе Хәбибрахман Зәбири истәлекләрендә ачыклык кертелә: «Беркөнне художник Зверевка барып «Су анасы» һәм «Безнең гаилә» дигән шигырьләргә карата рәсемнәр ясарга заказ бирдек. Тукай шулар артыннан йөри-йөри үзе җитәкчелек итте. Хәзер булгач та үзе алып кайтты, ләкин һичбер төсле канәгатьләнмәгәнлеген сөйләде». «Кара инде, шул да булдымы песи, рәсемнең иң мөһим ноктасы безнең песи икәнлеген аңлата алмадык шул. Йә инде, татарлар чәй эчәргә ярата дигәч тә ун чиләкле самовар ясап куймыйлар бит. Моның самовары нәкъ бабай кадәрле», – дип көлеп куя Г. Тукай.

«Күңелле сәхифәләр» китабына кертелгән тагын башка иллюстрацияләр дә бар. Галимнәр фикеренчә, әлеге иллюстрацияләрне Габдулла Тукай XX гасыр башындагы журналлардан кисеп алган һәм аннан соң шуларга туры китереп, үзенең



Г. Тукайның «Безнең гаилә» шигыренә иллюстрация («Күңелле сәхифәләр», 1910) китабыннан

әсәрен язган. «Шаян песи» әсәренә ясалган иллюстрация Британия рәссамы, акварилист Хэрриетт Мэри Беннетт рәсеменә охшатып әзерләгән. М. Беннетт иллюстрацияләрендә күбрәк балалар, этләр, песиләр сурәтләнә. Соңыннан алар Раштуа открыткалары буларак нәшер ителә.


«Мәктәптә милли әдәбият дәресләре» (1910, тышлыкта 1911) – Габдулла Тукайның үзенең шигырьләре генә түгел, ә чордашларның әсәрләрен кертеп төзегән татар әдәбияты дәресләре өчен хрестоматия. Биредә Тукай китаплары арасында беренче тапкыр тышлыкка эпиграф кертелә, шагыйрьнең «Туган тел» шигыреннән өзек урнаштырыла. Эпиграфлар кертү аннан соң бик актив кулланыла башлый. Мәсәлән, XX гасыр башында эпиграфлы дәфтәрләр дә чыга. 1911 елда Г. Тукай сурәте төшкән, аның «Эш» шигыренә өзек бирелгән дәфтәрләр нәшер ителә. Бакчасарайда, Исмаил Гаспринский музеенда тышлыкта И. Гаспралы фотосурәте урнаштырылган һәм Г. Тукайның «Ата илә бала» шигыре язылган дәфтәр дә саклана. «Күңел җимешләре» (1911) китабы да Г. Тукайның фотосурәте белән бастырылып чыгарыла һәм тышында «Күңел» шигыренең беренче дүртьюллыгы китерелә.

1908-1911 елларда Г. Тукай балалар өчен махсус китаплар чыгаруга зур игътибар бирә. «Мәктәп көтепханәсе» сериясеннән 1911 елда нәшер ителгән «Мияубикә» китабында песиләрнең 13 төрле варианты бирелә: уйчан, ауга әзерләнгән, йоклап яткан h.б. песиләр – барысы да Тукайның сурәтләү объекты буларак сурәтләнә.

**«Кара инде, шул да булдымы песи, рәсемнең иң мөһим ноктасы безнең песи икәнлеген аңлата алмадык шул. Йә инде, татарлар чәй эчәргә ярата дигәч тә ун чиләкле самовар ясап куймыйлар бит. Моның самовары нәкъ бабай кадәрле», – дип көлеп куя Г. Тукай.**



Тукаев Г. Сабитнең укырга өйрәнүе. Казан, 1912




Тукай Г. Сабитнең укырга өйрәнүе. Казан, 2024

«Сабитнең укырга өйрәнүе» беренче тапкыр 1912 елда Казанда И. Харитонов типографиясендә басылган «Татар әлифбасы» дигән китапка кушымта рәвешендә дөнья күрә. Типография хуҗасы татар язуы өчен махсус хәрефләр койдыра һәм, шуны халык арасында тарату ниятеннән, китап ике төрле шрифтта языла, төсле рәсемнәр белән бизәлә. Г. Тукай шигыренең герое да – белемгә омтылучы егет. Аңа әтисе «Харитонов бабай әлифбасы»н бүләк итә. Әсәрдә сабыйның укырга өйрәнү шатлыгы тасвирлана. Монда Сабит тә куана, әнкәсе белән әткәсе дә канәгать. Шагыйрь үзе дә укыган балага соклана.

Г. Тукайның вафатыннан соң да җыентыклары нәшер ителүен дәвам итә. 1913 елда алты китабы, тагын бер елдан соң ун китабы дөнья күрә. 1914 елда «Мәгариф» нәшриятендә күптән көтелгән, «Һәр өйдә бер нөсхә булырга тиеш китап» «Габдулла Тукай мәҗмугаи асаре» басыла. 1915 елда Петербургта чыга торган «Ил» газетасы билгеләп үткәнчә, «Габдулла Тукай мәҗмугаи асаре – әдәбиятымызда беренче мәҗмугаи асардер».

«Мәҗмуга өч төрле кәгазьдә бастырылган, иң очсызының хакы 1 сум 75 тиендер. Баш склады Казанда, «Мәгариф» көтепханәсендә. Башка мәшһүр китапчыларда да бардыр», – дип яза «Ил» газетасы 1915 елның башында. «Бәһасе гади кәгазьдә әҗза – 1 сум 7 тиен, мөҗәлләд – 2 сум, әгъла кәгазьдә әҗза – 2 сум 2 тиен, мөҗәлләд – 2 сум 55 тиен, коленкоровый мөҗәлләд – 3 сум, әгъла мөҗәлләд – 5 сум, бархат белән тышланган әгъла... – 10 сум. Пучта мәсарифы алучыдан. Задаткасыз налож йибәрелми», – дигән игъланны «Кояш» газетасының 1915 елгы 16 апрель санында укырга була.

Җыентыкның тарихы 1912 елның көзендә башлана. Клячкин хастаханәсендә ятканда да Г. Тукай эшен дәвам итә. Шагыйрьнең үләренә 40 көн кала, аның янына хастаханәгә барган нашир Шәһер Шәрәф Г. Тукайның, «Мәгариф»

көтепханәсе тәкъдиме буенча, үзенең бөтен язган шигырьләрен бер тәртипкә төзәтеп, «Мәҗмугаи асар» әзерләгән вакыты»на туры килә. Шул вакыт бәгъзы шигырьләрен бозып, төзәтеп утырган Тукай үзенең иҗатын: «Яшьлек берлә әллә нәрсәләр язылган, кайсыбер шигырьләремне күрәсем дә килми», дип бәяли.

Г. Тукай үлеменнән соң, китапны нәшер итү эше дәвам итә. Бу турыда вакытлы матбугатта, «Мәгариф» нәшрияты бастырып чыгарган китапларда хәбәр ителеп торыла: «Кыска гына хәятендә матбугат вә әдәбиятымыз дөньясына байтак сөйкемле чәчәкләр тезеп киткән мөхтәрәм шагыйремез Габдулла әфәнде Тукаев җәнабләренең таралып яткан шигырь вә нәсерләре «Тукай мәҗмугасы» намилә «Мәгариф» көтепханәсе хакында нәшер ителәчәге ... шагыйрь үлгән көндә, аның кабер якасында ук сөйләнеп, матбугат аркылы бәян ителгән бер фикер иде».

Җыентыкка тел һәм әдәбият галиме, тәнкыйтьче Җамал Вәлиди тарафыннан кереш сүз әзерләнә. Әлеге мәкаләдә Тукайның тормыш юлы һәм иҗаты беренче мәртәбә этрафлы яңгыраш тапкан. Мәҗмугада әсәрләр «Җитди шигырьләр», «Көлке һәм һәҗүв кыйсеме», «Балалар кыйсеме» исемле өч өлешкә бүленеп урнаштырылган. Әмма бүленешне үзенчәлекле колонтитулга (ул битнең өске өлешенә түгел, бәлки аска урнашкан) таянып санасак, җиде булып чыга: өчесе югарыда күрсәтелде, калган дүртесе «Шүрәле», «Халык моңнары», яңадан «Балалар кыйсеме», «Нәсер кыйсеме» дип аталган.

Җыентыкка шагыйрьнең 3 фотосы – 1908, 1911 елларда һәм Клячкин хастаханәсендә төшерелгән соңгы фотосурәте кертелгән.

«Мәҗмугада «Мәгариф» көтепханәсе тарафыннан махсус фотограф җибәреп ясалган алты фото да урнаштырыла: Г. Тукай туган Кушлавыч авылы; Кушлавычта Г. Тукай туган йорт; Кырлай авылында Фәтхрахман хәзрәт йорты (бу йортта Г. Тукай абыстайдан дәресләр ала); Өчиле авылында Зиннәтулла хәзрәт йорты (бу йортта Г. Тукайның әнисе Бибимәмдүдә туган; әнисе үлгәч бәләкәй Габдулла бу йортта торган; 1912 елда Өчилегә кайткач та, Тукай бу йортта булган); Кырлай авылында Г. Тукай укыган малайлар мәктәбенең ике фотосы (берсендә мәктәп Кырлай мәчете фонында). Тукай урыннары белән бәйле фотоларны беренче татар фотографларыннан Кыйвам Зөлфокаров (1870-1921) төшергән.

«Габдулла Тукай мәҗмугаи асаре» – татар китап графикасының беренче үрнәкләреннән берсе. Җыентыкта үзләренең тәэсир көче, экспрессивлыгы һәм эмоциональлеге белән аерылып торган 33 иллюстрация бар.

Татарстан Республикасы Милли музее тупланмасында «Б.Э.» имзасы белән билгеләнгән, «Габдулла Тукай мәҗмугаи асаре» өчен махсус ясалган җиде иллюстрация саклана: «Шүрәле» әкият-поэмасына – 3, «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш» поэмасына – 3, «Кәҗә белән Сарык» әсәренә – 1.

Мәҗмуганың тагын бер кыйммәте – биредә Г. Тукай автографы факсимилелары бирелә. Җыентыкка шагыйрьнең «Исемдә», «Васыятем» һәм шифаханәдә язган соңгы әсәрләреннән «Толстой сүзе», «Тәфсирме? Тәрҗемәме?» шигырьләре кульязмаларының фотокүчермәләре кертелә.

Гомумән, Габдулла Тукайның үзе исән вакытында 6,5 ел эчендә 147 000 нән артык тираж белән 33 китабы (кабатлап чыгарылганнарны һәм «Габдулла Тукай мәҗмугаи асаре»н санап) нәшер ителә. Китап сатучылар даими рәвештә вакытлы матбугатта яңа басмалар турында реклама урнаштырып торалар. Шуның белән бергә һәр китапның ахырында, соңгы битендә яңа китаплар турында мәгълүмат бирелә торган була.

Гомумән, Тукай фәнендә соңгы елларда шагыйрьнең үзе исән вакытында нәшер ителгән китапларына игътибар зур. 2021 елдан башлап Татарстан китап нәшрияты, Татарстан Республикасы Милли музее һәм Габдулла Тукай әдәби музее тарафыннан Габдулла Тукайның үзе исән вакытта нәшер ителгән китапларын кабаттан бастырып чыгару эше башланып китте. Бу проект кысаларында шагыйрьнең «Габдулла Тукай мәҗмугаи асаре», «Күңелле сәхифәләр», «Алтын әтәч», «Сабитнең укырга өйрәнүе» китаплары дөнья күрде.



Илдар Зарипов. «Җәй». 1991. Киндер, майлы буяу

# Татар аты

**(ДӨНЬЯ «АТ ЕЛЫ»НА КЕРДЕ. БУ ЯЗМА ШУЛ УҢАЙДАН)**

Галимҗан ГЫЙЛЬМАНОВ,
*язучы, әдәбият белгече*



БЕРЕНЧЕ КИСӘК

Татарны атлардан аерып карап булмый. Атларны – татардан. Телдәге «ир-ат», «исем-ат» дигән лигвистик янәшәлектән үк бу сүзнең никадәр сихри-магик көчкә ия булуы, никадәр көчле символ-код буларак каралырга тиешлеге аңлашыла. Татар образын, татар язмышын, татар идеясен тарихи, фәлсәфи, эмоциональ һәм генетик аспектларда өйрәнгәндә шушы сүз килә дә чыга, килә дә чыга...

Г. Ибраһимов «Казакъ кызы» романында шушы магик бәйләнешләрнең образлы мисалларын китерә. Менә әдип тәкъдим иткән халык җырларыннан бер мисал:

*Ат яхшысын сорасаң, –*
*Ир яхшысын күрерсең,*
*Тун яхшысын күрерсең,*
*Әндиҗан белән Коканда,*
*Кырым белән Казанда,*
*Хива белән Бохарда...*

Күренекле казакъ шагыйре Абай Кунанбаев үз милләте өчен атларның никадәр югары урын тотуы турында болай дип яза: «Безнең казакъ, яраткан аты бәйгедә алдан килсә, исен-акылын җуйганчы бер куана инде... Белмим тагын, шуннан да артык куанычыбыз бармы икән? Юктыр да» («Хикмәтле сүз»). Абайның бу хикмәтле сүзен татарларга карата да әйтергә булыр иде.

Ләкин борынгы төркиләр атны никадәр генә олыласалар да, юлдаш һәм яудаш буларак, аның кеше язмышындагы хаклы урынын дөрес билгеләргә тырышканнар. Ләкин бервакытта да кешедән өстен куеп табыну булмаган. Атларга шундый үзенчәлекле караш Чыңгыз хан заманында яшәгән шагыйрь, философ, астролог Әлүй-Чутсай шәхесенә нисбәт ителә. Бу легендар философ-шагыйрь Чыңгыз ханга: «Ат менеп дөньяны яулап була, әмма ат өстендә җиһанны идарә итеп булмый», дип әйткән, имеш... Ләкин, ничек кенә булмасын, борынгы төрки-татарлар атны «Алла мәхлугы» дип йөрткәннәр. Болгар бабалар ак һәм соры атларны изгеләштергәннәр, аларны, Тәңрене бәхилләтү өчен, корбанга чалганнар.

Атның борынгылыктан килгән символ-мәгънәләре күп.

Ат – дөнья халыкларында, шул исәптән төрки халыкларда да, иң мификлаштырылган, легендага, символга әверелдерелгән, милли код дәрәҗәсендә эшләнгән образ. Аның мифик төшенчәләрен санап бетергесез: Кояш, көн, вакыт, тизлек, җил, ут, яшен-күкрәү, яктылык, нур, шул ук вакытта – бәхет, бәрәкәт, тугрылык, язмыш, җиңү, яшәү (хәтта үлем), бер дөньядан икенче дөньяга күчү символы, гомумән, илаһи хайван. Төркиләрдә ул – Күк, Кояш, Яшен (Куар), Бәркет, Ут символлары белән бергә, Күк Тәңренең җирдәге илаһи-магик көчен, ихтыярын, бәхиллеген, игелеген, рәхмәтен гәүдәләндерүче образ. Еш кына ул мифологик символ, образ булып кына калмыйча, чын аллалар рәтендә карала башлый. Әйтик, тугандаш башкорт халкында, мәсәлән, «Акбүзат» дастан-кобаерында Ат 12 алланың берсе итеп тәкъдим ителә. Хәтта аңа табыну тәгълиматы барлыкка килгән. Алтай төркиләренең «Алтын Бизе» дигән эпосында күктәге баш алла күк атларын Җиргә төшерә. Җирдә алар ике тирәккә әвереләләр. Шуннан соң гына Алтай җирләре мал һәм бәрәкәт белән тула. Идел-Урал

татарлары риваять-легендаларында да ат рухлары, ат ияләре, ат ирәннәре хакында ышанулар, миф кыйпылчыклары сакланган. (Атлар рухы белән бәйле поэтик символ бүгенге татар поэзиясендә дә еш очрый.)

Гомумән дә, төрки мифологиядә Ат образ-символы тулысынча диярлек Күк белән, димәк ки, Күк Тәңре ихтыяры белән бәйләнгән. Канатлы ат Толпар – төрки халыкларда иң киң таралган образларның берсе, моны һәр татар баласы белә. Тагын шул мәгълүм: татарлар, Ат, туганда, канатлы булып туа, дип уйлаганнар; аны бары тик җиргә төшкәнче тотып алырга гына кирәк, дип ышанганнар (Г. Дәүләтшин). Атлар, туганда, куш йөрәкле булып туалар, дигән сүз дә борынгыдан килә. «Идегәй» дастанының татар вариантында шундый юллар бар: «Колагын бездәй кадаган, Кәгелен кыздай тараган, «Чу!» дигәндә, очкан кошны Узып китмәгә яраган, Йөргәндә эзен санаган, Куш йөрәкле яралган...»

Мифик атларның судан, җир астыннан чыккан очраклары да бар. Башкортларда, шулай ук татарларда киң билгеле булган «Курның улы», «Акбүзат», «Урал батыр» дастан-кобаерларда, «Тугыз улан» әкиятендә әнә шул су асты дөньясыннан чыккан атлар турында сүз бара. Ә менә Җир асты дөньясыннан чыккан ат Себер татарларының «Йир Төшлек» дастанында тасвирлана. Ханның туйда кияүсез калган кызы атасына болай ди: «Җиде кат җир астында, җиде кабат Тимер сарай эчендә унике җанлы *(унике йөрәкле! – Г. Г.)* Чал койрыгыңның бавыры астында алмас кылычы бар, аны бир миңа, атам». Бу текст буенча тагын шул аңлашыла: илаһи атлар туганда, бавыр астында яу кораллары белән туалар! Монда барысы да уйланылган: кыен хәлдә калган батырларга, каһарманнарга ярдәм иткәндә корал бик кирәк бит! Әйе, эпик герой тарафыннан могҗизалы атны кулга төшерү вакыйгасы – төрки-татар әкиятләрендә иң үзәк мотивларның берсе. Еш кына бу ат батыр белән бер үк көнне туган була, батыр аны өч мәртәбә сынап кулга ияләштерә. «Идегәй»дә – Тарлан бүз, «Ак байтал»да – Ак байтал, «Кузы Күрпәч белән Баян-Сылу»да Күктән төшкән ат – нәкъ шундый персонажлардан.

Мифларда, дастаннарда, әкиятләрдә каһарман белән аның аты – төп сюжетны, төп вакыйганы алып бара торган геройлар. «Алпамша», «Алтаин Саин Сөмә», «Әйгәли батыр», «Идегәй» дастаннарында, казахларның «Алпамыш», «Кобланды батыр» эпосларында, башкортларның «Урал батыр», «Акбүзат» кобаерларында батыр белән аның могҗизалы аты бер-берсенә тулысынча ышаналар; чынлыкта бөтен легендар сюжет әнә шул мифик атның тугрылыгын, фидакярлеген сурәтләүгә, кеше белән атның бер тиенгә берләшкән, уртак магик көчен, илаһи егәрлеген, язмышын тасвирлауга нигезләнә.

Атның вакыт, гомер, язмыш мәгънәсе Мәхмүд Кашгарыйның *«Диване лөгатет-төрк»* хезмәтенә дә төшеп калган: «Киши аласы ичтин, елкы аласы – тыштин». Ягъни: «Кеше аласы – эчтә, елкы (ат) аласы – тышта». **Кеше – ат янәшәлеге** турында мәкаль-әйтемнәр бүген дә туып тора. Мәсәлән: «Кешенең холкы – теле астында, атның холкы – тоягы астында». Атлар белән кешеләр янәшәлегенең әһәмиятен күрсәтә торган әйтем Мамадыш ягында да очрый. «Җәяүленең сукмагы җиде булса, атлының бер генә», – диләр Нократ буенда яшәүче татарлар. **Ат – кеше берле**ге хакындагы шушы бер мәкаль дә татарның милли характерын, асылын әйтеп бирә, минемчә: «Ир-егетнең эчендә иярләнгән ат ятыр», – диләр бездә.

Татарларның **мәкаль-әйтемнәр** фондында, хикмәтле сүз мирасында Ат белән бәйле мәкаль-әйтемнәр күп. Менә аларның кайберләре:

Ат – туйган җиренә, кеше туган җиренә кайта... («Идегәй»)

Ат тапсаң, ияр табыла.

Ат күрмәгән ат күрсә, абзарда атланып йөрер.

Ат кемнеке – менгәннеке, тун кемнеке – кигәннеке.

Ат аяган ат менәр, тун аяган тун кияр.

Ат егылса – көлмиләр, дөя егылса – көләләр.

Ат дүрт аяклы, алай да абына.

Дүрт аяклы ат та абына.

Ат кешнәшеп, кеше сөйләшеп таныша.

Ат башы белән уйнаганчы, атаң башы белән уйна.

Ат аягын дагалатканда бака ботын сузган (кыстырган).

Ат аунаган җирдә төк калмый булмас.
Ат арымаса, камыт арымас.
Ат алсаң, сынап ал, акча алсаң, санап ал.
Ат алмас борын йөгән эзләмә.
Арык атка камчы да авыр, көр атка таш та җиңел.
Арыган атка йөгән дә йөк (авыр).
Арканлы ат казыгына уралыр.
Кош – канаты, ат аягы белән.
Колан коега төшкәндә корбага (гөберле бака) айгырлык кылыр.
Чапкан атка гына җил каршы.
Баласы атка менсә, анасы ботын кыса.
Ялына ябыша алмаган койрыгына ябышып озак бара алмас.
Ишәкнең дәлиле – йөгән, атның дәлиле җилдән.
Яхшы ат дагасыз булмас, батыр йөрәксез булмас.
Ат үләр – дагасы калыр, батыр терелер – ярасы калыр һ.б.

Кешеләр белән атлар берлеге, «туганлыгы» хакында халык мифологиясендә күп дәлилләр бар. Татарлар элек-электән шуңа игътибар иткәннәр: һәркемнең үзенә тәңгәл килә торган аты була. Холкы, токымы, хәтта төсе, кыяфәте белән сиңа шул ат кына туры килә, имеш. Синең белән янәшә яшәүгә яраклы ат хакында «төсе килешә» дигәннәр, авыл кешесенә, аның хуҗалыгыңа туры килми торган (тынгысызлана, ашамый-эчми, ябыга, бертуктаусыз авырый, хәлсезләнә, ахыр чиктә үлә) ат хакында «төсе килешмәгән» дип сөйләнгәннәр.

«Идегәй» дастанын татар атлары турында үзенчәлекле энциклопедия дип әйтергә булыр иде. Нәкъ менә шушы мәшһүр чыганакта кеше язмышының ат язмышы белән тәңгәллегенә дан җырлаган атаклы юллар сакланып калган:

– Әй Идегәй, Идегәй,
Таяк тайга җиткерер,
Тай дүнәнгә җиткерер,
Дүнән атка җиткерер,
Ат морадка җиткерер!

*(Текстта атның үсеш этаплары санала. – Г. Г.)*

Халкыбызның мифологик мирасында **«Ат юраулары»**, атлар белән бәйле **әфсен-ырым**нар шактый күп сакланган. Менә шуларның кайберләре:

**Төшкә ат керсә** – сөенечкә, байлыкка.

**Төштә атка менсәң** – мәртәбәле булуга ишарә.

**Төштә атыңны суга батырсаң** – нәселеңнең, токымыңның, халкыңның каны коелачак. «Идегәй»дәге юрау:

Иделнең буе Ашлы су,
Ашлы суга ат салдым,
Акбүз атым батырдым...

Төш юраучы карт Туктамыш ханга болай дип юрап бирә:

Иделнең буе Ашлы су,
Тонык булса – ул кайгы,
Акбүз атың батырсаң,
Атыңны тоткан балчыгы –
Татарның каны булмасын...

**«Өере белән өч тугыз»** – мал бәйләгәндә яисә ат бүләк иткәндә әйтелә. Өерең өч тугызга артсын, димәктән.

**«Йөгергәндә җир бавырын кырдырсын!»** – элгәреге заманнарда йөгерек атларга атап әйтелгән ырымлы теләк («Идегәй» дастанында очрый).

**Чүл-дала сынавы (үсмерне балигълыкка чыгару)** – борынгылыкта балигълык яшенә җиткән егетләрне ябага атка атландырып билгеле бер вакытка (берничә айга) чүлгә, далага җибәрү йоласы булган. Яисә балигълык яшенә җиткән яшь-җилкенчәкне бик күп көнлек ерак юлга озатканнар. Бу йола хакында хәбәр «Идегәй» дастанына да төшеп калган:

Атаңа миннән кит, диеп,
Исән-аман җит, диеп,
Җабага тайга мендереп,
Чүл-далага озаткыл;
Сау калса үзеннән,
Сау калмаса, синнән калмыйдыр...

**Далага алып чыгып, атта йөртеп дәвалау йоласы.** Олугмөхәммәд ханны шулай терелткәннәр дигән риваять бар.

**Ат үз иясен терелтә ала**, дигән ышану бар. «Ат үз иясенең сулышын үз сулышына ияртер» дигән әйтем дә булган. Ат сулышы – иң тулы сулыш, ә аның йөрәге иң чырыш йөрәк, дип уйлаганнар.

**Ат тыны белән дәвалау булган. Бигрәк тә бизгәк белән авырган балаларга ат тынын (сулышын) өрдергәннәр.**

**Йөрәк авыруларын имләү** – атка атланып йөрсәң, йөрәкне тынычландыра, тын-сулышны көйли дип ышанудан.

**Ат зәхмәте** дигән шаукым да булган. Ыру-нәселгә, гаиләгә, бу нәсел кешеләре яшәгән хуҗалыкка төсе килешмәгән атлар белән бәйле бу шаукым. Һәрхәлдә, шулай дип уйлаганнар. Ат зәхмәтеннән арындыра, дәвалый торган мәҗүси догалар, магик догалар, арбау, имләү ысуллары булган, махсус ырымнар, әфсеннәр, им-том текстлары уйлап чыгарылган. Мәсәлән, томар дигән им-том догасы (бөти) хакында мәгълүматлар бар. Бу дога язуын атлар ялына бөтереп бәйләгәннәр. Әлеге бөти югалса, өзелеп төшеп калса, начарлыкка юраганнар.

**Атның койрык кылы тылсымга ия**, дигән ышану булган. «Ике дус» әкиятендә шундый магик-тылсымлы йола телгә алына: «Курыкма, минем ау (койрык) кылымны өзеп ал да, аны муеныңа бәйләп, кайнар сөттә коенып чык, синә бернәрсә дә булмас», – ди егетнең аты.

**Атны гомергә тиңләп (озын гомергә юрап) имләү** «Җигелсәң – мичәү, йөгерсәң – чәчәү, әкрен барсаң – калу, абынсаң – баш-күз еру...»

**Бүләккә бирелгән ат әфсене** – иң борынгы текстларның берсе, шулай ук дастаннарда еш очрый:

Тактайлаган бычкактай,
Табаны яссы йирән ат;
Киләпләгән йибәктәй,
Ялы булган йирән ат;
Чәчле кыздай, койрыгы
Ай-һай озын йирән ат;
Галәмне узып йилтә алган
Үгечем уктай йирән ат
Биргем синә, морза зат!

**«Тояк ялы»** – элгәреге дәверләрдә җыелган дәүләттән җиңүче файдасына бирелә торган махсус салым булган. Гадәттә, ул ат өер-көтүләре рәвешендә бирелгән. Кайчакта акчалата да, алтын-көмеш яисә тире-мех рәвешендә дә билгеләнгән.

**Билен бөккән** – аталандырырга орлык чәчкән ат хакында «тел яшереп» әйтелә.

**Ат башы сөяген инешкә салсаң, яңгыр явачак...** дигән ырым хакында Ләис Зөлкарнәевнең «Яңгыр яллы айгыр» шигырендә сөйләнелә.

Миф: **«Абзар иясе һәм атлар»**: Абзар иясе кайчакта атларның ялын үреп куя. Абзар иясе төрле хайваннарны үзенчә ярата һәм аларны төсләре буенча аера. Бигрәк тә аңа кара төстәге хайваннар, шул исәптән кара төстәге атлар да, ошамый, ул аларны чиргә сабыштыра яки бөтенләй юк итә...

Риваятьләрдә **ат тояклары батып кергән урыннарда изге күлләр барлыкка килүе** хакында сөйләнелә. Шундый риваять Сүбә күле хакында. Бу күл Чыңгыз ханның уң кулы Сүбүдәй баһадурның ат тоягы астында бәреп чыккан чишмәдән яралган, имеш. Шуңа күрә аның суы изге санала. Күп егетләрне яугирлеккә шушы күл буенда багышлаганнар. Сүбә суын эчкән яугирне кылыч алмый, сөңге урап уза, уклар аткан җирдән коелып кала, дип тәмамлана ул риваять.

Атлар турында, аларның яшәү рәвеше, холкы, җиһаз-җайланмалары, җайдаклары хакында күп **йомак-табышмаклар** билгеле. Бик борынгы заманнарда аларның күбесе яшерен телле магик әйтем-әфсеннәр, ырым теләкләре, шаукымлы текстлар булган. Күз тимәсен, кара рухлар игътибар итмәсен дип, борынгылар атлар янында яшерен тел – **табу теле** белән сөйләшкәннәр. Бу табышмаклар – шуларның серле кыйпылчыклары да булырга мөмкин. Бу серле телнең берничә үрнәгеен укучылар карамагына да тәкъдим итәм: **(чабышкы) ат** – утыргыч, койрыклы утыргыч; **(җигүле) ат** – Шабан агай; **дуга** – көянтә, кара көянтә; **камыт** – (бер күзле) кош; **тезген** – каптырым; **камчы** – сыптырым; **кыңгырау** – җизни аты, (алтын аяк) күбәләк; **ат кешнәү** – былбыл сайрау; **ат башына камыт кидерү** – чөйгә кош куну һ.б.

Атлар хакындагы табышмакларда әлеге серле телнең образлы гәүдәләнешен күреп, халыкның фантазиясенә сокланырга гына кала.

Калын арка,
Тарта да тарта,
Ул тарткан саен табыш арта. *(Ат)*
Дүрттер аның аягы,
Түбәсендә колагы,
Илдән-илгә җиткерер,
Таштыр аның тоягы. *(Ат)*

Койрыгы салпы,
Ике колагы кайчы.
Аны белмәгәннең сыртына –
Каеш камчы. *(Ат)*
Ул чапканда – мин басып торам,
Ул атлаганда – мин утырып торам,
Ул туктаганда – мин йөреп торам. *(Ат, җайдак)*

Алты аяклы, ике куллы, ике башлы, бер койрыклы. *(Атка атланган кеше, җайдак)*

Шулай ук ат җиһазлары белән бәйле табышмаклар да җитәрлек:

Утырган җирем – уй-чокыр,
Баскан җирем – бай чокыр,
Бер кулымда – каптырым,
Бер кулымда – сыптырым...
(Ияр, өзәңге, тезген, камчы)

Аттан биек, эттән тәбәнәк. *(Ияр)*

Ит казанда тимер кайный. *(Авызлык)*

Типтем – тимер, утырдым – уек. *(Өзәңге, ияр)*

Ишектән сөйрәлеп керә, озын чөйгә менә. *(Камыт)*

Чөй-чөй, чөйдем кош,
Чөй башына менде кош. *(Камыт)*

Атка атланыр,
Үзе утырмас.
Арбага менмәс,
Җәяү йөрмәс. *(Дуга)*

Тырыс-тырыс, тырыстан,
Тырыс килә урыстан. *(Дуга кулчасы)*

Ат башында кара көянтә. *(Дуга)*

Ыңгырлы да шыңгырлы,
Атка менсә, шылдырлы. *(Ыңгырчак)*

Аттан югары, көчектән алаша (тәбәнәк). *(Ыңгырчак)*

Җиз сарайның эчендә җизни аты кешнидер. *(Кыңгырау)*

Җиз самавыр кайныйдыр, җизнәм аты кешнидер. *(Кыңгырау)*

Алтын алачык эчендә алтын колыным кешни. *(Кыңгырау)*

Гүрнәчәдә кыз җырлый. *(Кыңгырау)*

Минем җаным булмаса да, кыйнасаң – кычкырырмын *(Кыңгырау)*

Тиллим-тиллим көйлимен,
Җиз сарайда биимен. *(Кыңгырау)*

Атым аранда, тавышы яланда. *(Кыңгырау)*

Җыен-сабан туенда көйли киртә буенда. *(Кыңгырау)*

Сөйләшәм телсез,
Кычкырам тамаксыз,
Йөрәгем юк, борыным бар. *(Кыңгырау)*

Ике күчәр – Дөнья кичәр. *(Арба)*

Армый, талмый, ат артыннан калмый. *(Арба)*

Очырмада өч кошым бар, берсе: «Җәйне яратам», – ди, берсе: «Кышны яратам», – ди, берсенә җәй дә бер, кыш та бер. *(Арба, чана, ат)*

Берсе җәйгә елый, берсе кышка елый, берсе гомергә (яисә җәй дә, кыш та) елый. *(Арба, чана, ат)*

Берсе: акны яратам, ди, берсе: караны яратам, ди, өченчесе: миңа икесе дә бер, ди. *(Чана, арба, ат)*

Җәен май эчәр, җирне-суны кичәр, кышын ял итәр. *(Арба күчәре)*

Дүрт туган ике юлда, берсен-берсе куып җиталмыйлар. *(Арба тәгәрмәчләре)*

Дүрт кодагый, берсен-берсе куалый. *(Арба тәгәрмәчләре)*

Дөбер-дөбер дүртәү, агай-эне икәү, Шабан агай шып ялгыз. *(Арба тәгәрмәчләре, ат)*

Ерактан теңгер-теңгер,
Якыннан – табаны тимер. *(Арба, аның тәгәрмәчләре)*

Дөбердеге дүртәү, утыргычы берәү, йөртүчесе икәү. *(Арба, аның тәгәрмәчләре, ат һәм ат йөртүче)*

Тубыр, тубыр дүртәү,
Имән агач икәү.
Мыймылдыгы берәү,
Шыбагасы шып ялгыз.
*(Арба тәгәрмәчләре, тәртәләр, дилбегә, ат)*

«На!» дисәң, бармый, «Тпру!» дисәң, туктамый, печән салсаң – ашамый *(Чана)*

Әнә килә берәү –
Кәкре имәнгә терәү.
Йомычкадан кыз ясап,
Кияүгә биргән берәү. *(Чана)*

Ишек,
Ишек өстендә бишек.
Урамда йөри,
Кабыргасы тишек.
*(Арба һәм аның өстендәге мичкә)* ✿

(Ахыры киләсе санда)



Расиха ФАИЗОВА

# «ЗӨБӘРҖӘТ»ЛӘР КАЙДАН ДА, *«Төннек бәйрәме» кайда?*



**«ЗӨБӘРҖӘТ» – ДИЮГӘ КЕМНЕҢДЕР КҮЗ АЛДЫНА ӘЛЕГЕ ЗАТЛЫ ИСЕМНЕ ЙӨРТҮЧЕ ТАНЫШ-БЕЛЕШЕ, КЕМНЕҢДЕР ЯШЕЛ ТӨСТӘГЕ КЫЙММӘТЛЕ АСЫЛТАШ (ИЗУМРУД) КИЛЕРГӘ МӨМКИН. Ә ШӘЛЕЛЕЛӘР БУ ИСЕМНЕ, ҺИЧШИКСЕЗ, АВЫЛ МӘДӘНИЯТ ЙОРТЫНДА ЗӨЛФИЯ ГЫЙНИЯТОВА ҖИТӘКЧЕЛЕГЕНДӘ УТЫЗ ЕЛГА ЯКЫН ЭШЛӘП КИЛҮЧЕ ҺӘМ ӘЛЕ КҮПТӘН ТҮГЕЛ ГЕНӘ МӨХӘММӘТ МӘҺДИЕВ ӘСӘРЕ БУЕНЧА ТӨШЕРЕЛГӘН «КЕШЕ КИТӘ – ҖЫРЫ КАЛА» ФИЛЬМЫНДА ТӨШҮ БӘХЕТЕНӘ ИРЕШКӘН «ЗӨБӘРҖӘТ» ФОЛЬКЛОР АНСАМБЕЛЕ БЕЛӘН БӘЙЛИЯЧӘК.**



Шәхсән үзем «Зөбәрҗәт» фольклор ансамбелен беренче күрүдә үк күптән күргән-белгән танышларым янында кебек хис иттем. Әлеге очрашу, ирексездән, СССРның һәм Россиянең халык рәссамы Харис ага Якупов (1919-2010) белән Питрәч районының Шәле уңганнары турында сөйләшеп утырган мизелләрне искә төшерде. Харис аганың иҗади мирасында аерым бер урын биләп торган данлыклы Шәле шәкелен кем генә хәтерләми дә, кем генә белми икән соң?! Заманында Мулланур Вахитов исемендәге колхозның бөбәй итәкле күлмәк, канатлы алъяпкыч киеп, яулыкның аркага җәеп салганы өстенә тагын берсен маңгайдан чөеп бәйләгән уңган-булган киленнәрен бөтен СССРга таныта рәссам. «Һай, күңелле чаклар иде», – дип искә алган иде Харис ага Мишә буенда көтүчеләр корып биргән шалашта иҗат белән узган җәйләрен юксынып. Утыз еллап хуҗалык рәисе булып эшләгән Фәйзи Сафин белән генә түгел, үзе сурәткә алган терлекче кызлар, ханымнар белән дә гомеренең ахырына кадәр аралашып, хәл-әхвәл белешеп яши рәссам

гаиләсе. Чехов базарына азык-төлек алырга барсалар да, Шәленең шунда катык-сөт белән алыш-биреш итүче апайлары, аларны ерактан ук танып, сәламли торган булганнар. Торымнан-торымга Шәледән рәссамга атап бәйләнгән йон оекбашларга кадәр килеп торган. Харис агадан: «Бөтен халык кибет киштәсеннән алынган нейлон һәм джерси күмәкләрдән йөргән елларда бу кадәр дә «авылча стильный» ханымнарны кайдан казып чыгардыгыз соң?» – дип сораганым әле дә хәтердә. Һич кенә дә рәссамның хыялында туган образлар булмый алар. Казанның Халык хуҗалыгы казанышлары күргәзмәсендә йөргәндә терлекчеләрнең фотоларына юлыгып, исе-акылы китә рәссамнең. Әлеге павильонда кизү торучы егетнең шул колхоз зоотехнигы икәнен белеп, барын да төбенә тоз салганчы сораштыра торгач, Шәлегә ничек барып җиткәнен дә сизми кала. Баксаң, терлекче хатын-кызлар, чынлап та эшкә шундый киемнәрдән (!) йөри икән бит. Чып-чын табыш була ул рәссам өчен.

## ИКЕНЧЕ СУЛЫШ ӨРЕТЕЛГӘН КҮЛМӘКЛӘР

...Һәм менә дистә еллардан соң да Питрәч районы Шәле авылы үзешчәннәре – «Зөбәрҗәт» фольклор ансамбелен без әти-әниләре, әби-бабаларыннан калган сандыклардан чыккан, заманында Харис ага Якуповны «ах» иттергән киемнәрдән күрәбез. «Башваткыч»тамы, «Җәвит кәмиттә кунакта»мы, яки «Иске Казан» түгәрәк уенында булсынмы, «Чатыртау җыены»ндамы, «Татарстан – туган йортыбыз» фестивалендәме – мәшһүр рәссам үзенең үтә дә җете-колоритлы картиналарына иңдереп тарихта калдырган данлыклы сыер савучылар Фәүзия, Сәлимә, Бибия апайлары кебек үк канатлы алъяпкычлар, бишәр кат бәби итәкле күлмәкләр киеп, «француз» яулыкларын чөеп бәйләгән «әкәй»ле «Зөбәрҗәт» чибәрләрен шундук танып алалар. (Башы белән бәйләнгән, ягъни аркага җәеп салган яулык өстеннән маңгайны каплап торырлык итеп чөеп бәйләнгәне шәлеләр телендә «әкәй» дип атала).



**«Уракка төшү» йоласы**

– Ышанасызмы-юкмы, бу күлмәгем, үзем белән бер яшьтә – 1954 елгы. Авылдашыбыз Мансура апайныкы ул. Үзем тегү теккән кеше булырак, күлмәкнең өлгесен күреп шаккаттым, – дип сүз башлый «Зөбәрҗәт»че, гомер буе мәктәптә физика һәм кызларга технология укыткан Эльвира Нәҗмиева. – Арты тоташ, алды билдән өзек. Җитмәгән җирләренә өстәп ялгый-ялгый теккәннәр. Бөрмәләренең ешлыгын күрсәгез икән. Шуның өстенә җиңнәрен, аркасын ике катлы итеп теккәннәр. Монысы сакчыллык галәмәте булса кирәк. Тиз генә тузмасын, диюләре булган ахры.

Шуңа күрә дә бу күлмәкләрне бик саклап, кадерләп кенә кияргә тырышалар. Башкача мөмкин дә түгел – буыннан-буынга килүче ядкәр ич!

ЗАМАНЫНДА МУЛЛАНУР ВАХИТОВ ИСЕМЕНДӘГЕ КОЛХОЗНЫҢ БӘБӘЙ ИТӘКЛЕ КҮЛМӘК, КАНАТЛЫ АЛЪЯПКЫЧ КИЕП, ЯУЛЫКНЫҢ АРКАГА ҖӘЕП САЛГАНЫ ӨСТЕНӘ ТАГЫН БЕРСЕН МАҢГАЙДАН ЧӨЕП БӘЙЛӘГӘН УҢГАН-БУЛГАН КИЛЕННӘРЕН БӨТЕН СССРГА ТАНЫТА РӘССАМ

– Халкыбызның онытыла барган борынгы гореф-гадәтләрен, йолаларын өйрәнеп, кабат торгызабыз. Репертуарыбыз бай. «Урак уру», «Өй юу өмәсе», «Бәбкә саклау», «Каз өмәсе», «Кыз урлау», «Боз озату» һәм Бөек Җиңүнең 80 еллыгына багышлап эшләнгән «Он тегермәнендә» дип аталган чыгышларыбызны кайда гына күрсәтсәк тә, тамашачы бик җылы каршылый, – ди мәдәният йортының сәнгать җитәкчесе Зөлфия Насыйбулла кызы Гыйниятова.

Авыл белән бәйле шигырьләрне, бәетләрне, бәйрәм сценарийларын да үзе яза ул. Соңгы вакытта бөтенесен аякка басырып «Төннек бәйрәме»н сәхнәләштереп йөрүләре. Ул нәрсә һәм аның нинди булачагы әлегәчә күпләргә сер булып кала бирә.



**Зөбәрҗәтләр җыенына китеп барыш**

Иң мөһиме шуның кадәр дә бөртекләп җыйган мәдәни мирас өлкән яшьтәге апайлар белән бергә китеп онытылыр инде дигән шикшөбһә юк Шәледә. Ни өчен дигәндә «Зөбәрҗәт»нең үкчәсенә диярлек басып килүче үз иярченнәре-дәвамчылары – «Чабата» балалар фольклор төркеме бар. Быелгы Бөтенроссия «Каз өмәсе» фестивалендә 2нче урынга лаек коллектив ул. «Артка чыгу» (су буенда кичке уен), «Сугышка озату», «Сарык көткәндә», «Каз өмәсе» кебек йолаларны сәхнәгә куеп, «Уен – Fest», «Всероссийская фольклориада», «Этномириада», «Наш дом – Татарстан» кебек күп кенә конкурс, фестивальләрдә катнашып килә алар. Җитмәсә 2024 елда грант отып, затлы милли костюмнарга ия булганнар.

## ӨЙ ЮУ ЙОЛАСЫ

Институтта бергә укыган Фәрит атлы егеткә кияүгә чыгып, Шәлегә килен булып төшкәч, үз кануннары белән яшәүче бу авылны чын-чынлап яраткан Эльвира ханым да. «Чагыштырып карасаң, монда бер генә нәрсә дә башка авыллардагыга ошамаган. Бар да үзгә. Шәхсән миңа өй юу йоласы бик тә хикмәтле булып тоелды. Дөрес, ул безнең Әтнә районында да бар, әмма аны мондагы кебек тамашага әйләндермиләр. Биредә йорт эчендә булган бөтен нәрсәне тышка чыгарып бетереп, өйне мунчалалап юасың, аннан әйберләрне, бөртекләп кагасын кагып, юасын юып кертеп урнаштырасың. Эш бетүгә өмәчеләрне мунча һәм бәлеш көтә. Сиңа өмәгә 8-10 кеше килә икән, үзең дә аларга ярдәмгә барасың. Берәр ай буе йөрисең шулай өйдән-өйгә кунак булып», – дип сөйли Эльвира ханым.

## КЫЗ УРЛАУ

Кырык елдан артык Казанда гомер иткәннән соң гасыр кичкән әтисен тәрбияләргә дип авылга күченеп кайткан Зәйтүнә Фәттахова «Зөбәрҗәт» ләргә килеп кушылуын язмыш бүләге кебек кабул



**«Өй юу йоласы» сәхнәдә**

итә. Яшьлегендә артист булырга хыялланган ханым Шәленең канатлы алъяпкычындагы бер серне ачып салды. Өч бармак сыешлы гына итеп тегелгән яшерен кесә ул. Кич утырганда егетләр биргән хатларны кызлар кеше-кара күргәнче шыпырт кына алъяпкычтагы шул кесәгә шудыра торган булганнар.

Шәле – менә шундый хикмәтле йолалар авылы. Аның иң көттәсе – кыз урлау. Дөрес, бер дә күрмәгән-белмәгән, сөйләшмәгән кызны кычкыртып урлау юк, дип ышандыралар. Эш шуңа барып җиткәндә, егет кызга, кыз егеткә күз атып үзара аралашып йөргән була инде. Хуш, урлады да, ди, ә кыз күнмәсә, нәрсә була диярсез. Ризалашмыйча кире ата йортына кайткан кызга «арбадан төшеп калган» дип карау бар икән. Шуңа күрә кызлар башта ялындырып торсалар да, урлаган егеткә кияүгә чыгарга ризалаша ди.

– Мине 1977 елда кич клубка чыккан җирдән урлап алып киттеләр. Аллага шөкер, бик бәхетлемен, өч ул үстердек, җиде оныгыбыз бар, аларның иң олысы да 20не узды инде. Ирем Илнур дөнья бәһасе кеше, бик ярдәмчел, тырыш булды, – дип тормыш баскычлары буйлап янә үткәндәй итте хатирәләргә бирелгән Наилә Сафина.

Кыз урлауның тәртибе монда шундыйрак икән: егет кызны төп нигезгә түгел, йә апасы, йә берәр туганының өенә алып кайта. Анда, билгеле инде, булачак киленне каршыларга әзерләнеп торалар.

– Безнең заманда кызны алып кайткан йортта өчәр кич куну гадәте бар иде, – дип сүзен дәвам итә Наилә ханым. – Кызлар арасында, урлап алып кайткач, кадерлерәк тә буласың дигән фикер дә яши. Кызлары кич кайтмагач, аның әти әнисе иртәнге сәгать белән аяк өсте була инде: коймагын пешереп, чәен куеп хәбәр көтә. Күңелләре барыбыр нидер сизә, йә булмаса кызның дус-ишләре кичтән үк «урладылар» дигән хәбәр җиткергән була. Озак көттерми генә егетнең әти-әнисе: «Без сезнең алда гаепле инде, кызыгызны урладык», – дип кыяр-кыймас кына булачак кода-кодагыйлар йортына килә. Бу йолалар бүген дә саклана, әмма соңгы вакытта кызны сорап алу гадәте дә кереп киткән.

Бу авыл кызларын Шәленең үзендә генә түгел, башка якларда да урлау очраклары булуын беләм. Терлекче Миңзифа Галиуллина белән... дөресрәге аның рәссам Харис Якупов ясаган портреты белән дә шулай килеп чыга бит. Берлинда узган академик күргәзмә вакытында чибәр кызның портретын көпә-көндез урлап китәләр. Язмышларына шулай язылгач, Шәле кызларын кайда да урлыйлар икән шул.

## КАЗ ӨМӘСЕ

Каз өмәләрен дә биредә гөр китереп уздыралар. Аштан калсаң да өмәдән калма дибез бит. Шундый өмәләрнең берсендә елы-елы белән каз-үрдәкне йөзәр-йөзәр итеп алып үстерүче Наилә һәм Илнур Сафиннарның кунакчыл йортында үземнең дә катнашканым булды. «Хуш киләсез, аяк-кулларыгыз җиңел булсын, казларыбыз симез булсын», – дип такмаклый-такмаклый хуҗалар капка төбенә үк чыгып каршылый өмәчеләрне. Күңелең җитеп, зурлап уздыра калсаң, үзе бер хәйран-тамаша инде ул өмә дигәннәре. Чишмә буена каз чайкарга төшкәндә юл буенча канат чәчеп барулар үзе бер тамаша, үзе бер хикмәт бит.

Наилә ханым да «Зөбәрҗәт»тә очраклы кеше түгел. Күңеле мөлдерәмә тулы моң аның да. Ильмира Нәгыймова җырлый торган «Кара әле күземә» җырының сүзләре нәкъ менә Наилә Сафинаныкы бит! Шул җыры белән «Болгар радиосы»ның IX Милли музыкаль премиясенә лаек булган. Өмәгә дә ул гомер буе авылда иңгә-иң гомер кичергән дус кызлары «Зөбәрҗәт»ләрне дәшкән иде. Кырык елдан артык фермада сыер сауган Рәисә Гайнетдинова белән дә шунда танышкан идек. Ул да ансамбль оешканнан бирле сәхнәдән төшмәгән. «Җитәкчебез бер сызгыруга килеп җитәбез, өмәгә көненә ике тапкыр чакырсалар да барабыз», – дип чатнап тора алар чордашы Гөлфирә Галиева белән.

– Авыл халкы тәүлекнең бер генә сәгатен дә әрәмгә уздырмый. Арыдым дип тормый, кич утырып, җебен дә эрли, шәлен дә, оекбашын да бәйли. Әнием Сания Насыйбуллина гомер буе кул эше тотты. 87 яшендә дә оекбашлар бәйли

иде әле, – дип сөйли Гөлфирә ханым. – Каз өмәләре бездә электән үзенә күрә бер бәйрәм иде. Өлкәннәр каз йолкыганда бала-чага май канаты бәйли торган иде. Эш беткәч яңа мамыктан мендәр тутырыр идек. Ул көнне әби казларның эч-башыннан бәлеш сала, билгеле инде мичтә теләсә-кайсы мәҗлестә табын күрке булган Шәле коймагы да чыжламый калмый. Аны бүгенге көндә дә мичтә пешерәләр, – дип, авыл баласының һәрберсенә таныш булган хатирәләрне яңартып алды ул.

Һәр якның үз тәртибе. Монда исә өмә буласы йортта иртәнге сәгать белән бакчадагы зур казанда су кайнатырга дип учак тергезеп җибәрәләр. Суеп, канатларын алуга ук, казларны кайнап торган шушы суга чумдырып, пешекләп алачаклар. Болай эшләгәндә йолкырга да җайлы, мамыгы да чистарак була диләр. Беләккә кадәр калын резин перчаткалар киеп куйгач, пешәм дип куркасы да юк.

ИҢ МӨҺИМЕ ШУНЫҢ КАДӘР ДӘ БӨРТЕКЛӘП ҖЫЙГАН МӘДӘНИ ЯДКӘРЛӘР ӨЛКӘН ЯШЬТӘГЕ АПАЙЛАР БЕЛӘН БЕРГӘ КИТЕП ОНЫТЫЛЫР ИНДЕ ДИГӘН ШИК-ШӨБҺӘ ЮК ШӘЛЕДӘ

– Өмә дигәндә гармунчыларыбыз да ялындырып тормый, сәгате-минуты белән килеп җитәләр. Мондый чакта авылда гына җырлана торган борынгы «Үрмәкүч» җырын да башкармый калмыйбыз, – дип сүзгә кушыла Зөлфия ханым.– Ул менә болайрак...

*Агыйделнең аръягында болыт тора,*
*Яңа ярлар иске ярны оныттыра.*
*Яңа ярлар табак-табак аш китерә,*
*Иске ярлар күзләреннән яшь китерә.*

*Агыйделнең аръягында куян качты,*
*Ул куянны куа-куа карным ачты.*
*Ач тамакны туйдырырга бик күп кирәк,*
*Кызлар белән сөйләшергә хәйлә кирәк.*

*Бер үрмәкүч үзе өчен оя корган,*
*Оясын ул җепләр белән чорнап алган.*
*Ул үзенең тырышлыгы аркасында,*
*Түшәм кадәр биек җиргә менеп калган...*



**Каз өмәсе йоласы**





«Каз бәлеше әзер», – ди хуҗабикә Наилә Сафина

– Милли йолаларыбыз бихисап, аларны энҗе бөртекләрен тезгән шикелле берәм-берәм барлап, әманәт итеп киләчәк буынга тапшыру хәзер безнең өстә. «Язгы чәчүгә чыгу» йоласымы ул, «Карга боткасы»мы, «Уңыш бәйрәме»ме, – һәркайсының үз урыны бар. Хәтта балалар бакчасында «Татар кызчыгы», «Татар малае» кебек бәйгеләрне уздырганда да, без сабый күңеленә милли йолаларыбызны сеңдерүне максат итеп куябыз. Ата-бабадан килгән гореф-гадәтләрне саклап-санлап яшәгән милләт рухи яктан нык була, – ди «Ак калфак» иҗтимагый оешмасының район бүлеге җитәкчесе Лилия Хәмит кызы Гатиатуллина.

Үткәне дә бүгенгесе дә матур Шәленең. Биредә тарихны, йолаларыбызны, гореф-гадәтләребезне барлап яшәүче «Зәбәрҗәт»ләр белән беррәттән, элеккеге кебек үк балта осталары, челтәрләп тәрәзә йөзлекләре эшләүчеләр, көянтә, комган, ясаучылар да авылдашларын гел сөендереп тора. Болардан башка Мәдәният йортында эшләп килүче «Халкымның алтын бөртекләре» дип аталган музей да барлыкка килә алмас иде.

Фотолар «Зәбәрҗәт» фольклор ансамбле һәм автор фотоархивыннан

# РУХИ МИРАС *сагында*

Айдар ФӘЙЗРАХМАНОВ,
*Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясенең һәм Татарстан Республикасы Фольклор музыкасы дәүләт ансамбленең сәнгать җитәкчесе, Россиянең атказанган, Татарстанның халык артисты, Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, профессор*



**О. Акимичева фотосы**

«Түгәрәк уен»га мин 11-12 яшьләремдә үк килеп кергән кеше, шуның өчен дә әлеге исемне йөртүче журнал да күңелемә бик якын. Элгәре авылларда һәр көнне кичке уеннар була торган иде. Аны бездә «вечер» дип йөртәләр. Җәй көннәрендә ул болында, кышын авыл клубында уза. Түгәрәк уенда җырлап әйләнәләр, ә уртадагы кеше кемнедер чакыра һәм ул я җырларга, я биергә тиеш. Мин баянда уйнагач, авыл яшьләре әти-әнием янына «Бибинур апа, Фәтхрахман абый, безгә баянчы кирәк, Айдарны алып торыйк әле», – дип киләләр. Билгеле инде, егетләр, кызлар янына бик уңайсызланып кына барам, кайвакыт оялуымнан хәтта аларга артым белән утырып уйный торган идем. Баксаң, фольклорга якынаю минем өчен әнә шул «түгәрәк уен»нарда ук башланган икән.

КДУның татар бүлеге студентлары белән фольклор экспедициясендә йөрүләр дә очраклы булмаган. Бу 1974 еллар, минем Казан дәүләт педагогика институтының музыка факультетында 2-3нче курсларда укыган чак. Омск, Томск якларына, Иртыш буйларына фольклор материалы җыярга экспедициягә чыгып киттек. Иртыш елгасының уң як ярында урнашкан татар авылларын, андагы яшәү рәвешләрен күреп, җырларын язып алып, фольклорчы Роза Исхакова-Вамбага кайтарып тапшырдык. Казан Дәүләт консерваториясендә укыганда татар галиме, әдәбиятче, фольклорчы, тюрколог, КДУ профессоры Марсель абый Бакиров тулай торакка килеп кодалап, мине татар теле һәм әдәбияты бүлеге студентлары белән тагын да шул баянчы-музыкант сыйфатында, Курган өлкәсенә чыгарып җибәрде. Миңа гадәттәгечә студентларның концертларын оештыру бурычы йөкләнде. Безнең белән фольклорчы-музыкант Котдус Хөснуллин да бар. Шунда мин Халисәм – үземнең булачак хатыным Х. Рәхимова белән танышып кайттым. Ике елдан соң өйләнештек тә. Курган өлкәсендә саф ана телендә җыелышлар алып баруларын күреп ис-акылларым китеп кайттым. Әллә кайдагы Курган өлкәсендә бит бу! Шул рәвешле тормыш сукмаклары мине әкрен-әкрен генә фольклорга якынайтканын сизми дә калганмын.

2002 ел. Минем Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет театрында опера солисты булып эшләп йөргән чак. Бер үк вакытта телевидениедә

**Элгәре авылларда һәр көнне кичке уеннар була торган иде. Аны бездә «вечер» дип йөртәләр. Җәй көннәрендә ул болында, кышын авыл клубында уза. Түгәрәк уенда җырлап әйләнәләр, ә уртадагы кеше кемнедер чакыра һәм ул я җырларга, я биергә тиеш.**

«Җырлыйк әле» тапшыруын алып барам, Казан дәүләт педагогика институтының музыка факультетында җыр кафедрасын җитәклим. Һич уйламаганда миңа Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе каршында оешкан Фольклор музыкасы дәүләт ансамблен җитәкләргә тәкъдим ясыйлар. Мәшһүр җырчыбыз Илһам Шакиров белән филармония директоры Әсхәт Сафин тәкъдиме була ул. Билгеле, бу тота-каба ризалаша торган вазифа түгел, җаваплылык баштан ашкан.

Бер ай буе уйланып йөргәннән соң, рәхмәтләремне әйтеп, тәкъдимне кире кагасы иттем. Шулай да Илһам абыйның басымы белән бер ел эшләп карарга күндерделәр. Репертуар туплау мәсьәләсе беренче көннән үк килеп басты. Уен кораллары, костюмнар, коллективның иҗади мөмкинлеген ачыклау... һәммәсе мөһим.

Фольклор материалларын табу, туплау ул бик четерекле эш. Шунысы да бар, һәр тапкан әйберне сәхнәгә чыгарып, тамашачыга җиткереп тә булмый. Кулга килеп кергән материалның күбесе бәетләр, зур сәхнәдән халыкка тәкъдим итәрлек мелодик әсәрләр дә юк дәрәҗәсендә. Борынгы рухи мирасыбызны эзләп, әлбәттә, архивларга юл алдым. Фольклорчылар тарафыннан җыйналган материалларның нинди халәттә булуларын күреп бик борчылып, аптырап кайткан идем, әмма Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте белән, заманалар үзгәрде, ул материалларны цифрлаштырдылар, һәм шуларның бер өлеше минем кулга килеп керде. Аннан тыш та миңа чит илләрдән меңәрләгән материал алып кайта башлаган иделәр. Тик анысының да нибары 5-10 проценты гына киң тамашачыга тәкъдим итәрлек булып чыга.



Әле ул 5 процентны башта шул меңнәр арасыннан эзләп табарга кирәк бит. Чит илләр белән аралашу киткәч, без Финляндиядә, Кытайда яшәүче милләттәшләребез белән бу юнәлештә максатчан эшләдек. Кытайда яшәүче татарларның «Әти-әни», «Лимонад»; Финляндиядә яшәүче милләттәшләребезнең «Ай әле бик еракта идек без» дигән җырлары бүген безнең репертуарда. Тулаем алганда фольклор музыкасы дәүләт ансамбле репертуарында 150дән артык җыр бар.

Тагын бер әйбергә – биюләргә тукталасым килә. Татар биюләре бик күп һәм төрле. Мәсәлән, Омск, Томск шәһәрләрендәге биюләр белән Ульян өлкәсендәге, яки Татарстандагы биюләр бер-берсеннән нык аерылып торалар. Самара өлкәсендә «вакка басу» бик нык таралган, «Ярмәк вагы» дип тә йөртәләр аны. Вак-вак басып бию ягъни. Ульян өлкәсендәге «шестяк» дигәнендә кара-каршы басып алты кеше бии. Көйләре дә, хәрәкәтләре дә үзгә. «Чабата»ны алсак та шул ук күренеш: Балтач районында ул бер төсле, Питрәч, Мамадыш районнарындагы керәшеннәрдә «Керәшен чабатасы» бөтенләй башка. Ансамбльнең табышы булырдай номерларыбыз байтак. Мисалга «Ярмәк вагы»н инструменталь әсәр буларак тәкъдим итәбез. Монда мин үзебездә булган бөтен милли инструментларны (бөтен төрки халыкларга хас булган барабан – давыл, кырлы бәләк, тальян, думбра һ.б.) күрсәтә алам. «Думбра» дигән җырыбызны думбраларда уйнап башкарабыз. Г. Тукайның «Бишек җыры»н гөсләдә уйнап җырлыйбыз. Илһам Шакиров та заманында: «Халыкның онытылган яки онытыла бара торган уен кораллары күп бит. Шуларны торгызып халыкка ирештерәсе иде. Бу инде үзенә күрә бер ренессанс (яңарыш), милли байлыгыбызны күрсәтү булыр иде. Әйтик, курай, кубыз, саз, ятаган, гөслә, думбра», – дип хыяллана булачак фольклор музыкасы ансамбленең иҗат кыйбласын күзаллап.

Тамашачыга нәрсә генә тәкъдим итсәк тә, безнең сәхнә хәрәкәтләребез дә, җырларыбыз да, уен коралларында уйнавыбыз да, килеш-килбәтебез дә бүгенге заман таләпләренә туры килерлек камил булырга тиеш. Шөкер, костюмнарыбыз тегелә, уен коралларыбыз,



аппаратурабыз, транспортыбыз һәммәсе бар. Безгә җиң сызганып эшләргә генә кала. Бу урында Илһам абый Шакировның сүзләре васыять урынына яңгырый: «Шул фольклор ансамблен теләсә нинди урында, теләсә кайсы халык алдында күрсәтерлек булсын иде, кыскасы тирән милли, югары профессионал булса, ул инде интернациональ дә була». Ул хаклы, төрле елларда дөньяның 30-35ләп илендә (Австралия, Алмания, Польша, Төркия, Финляндия...) татар милләтенең йөзен, күңел байлыгын күрсәткән чыгышларыбызны мөкиббән китеп карап, аяк өсте басып алкышларга күмделәр, әмма соңгы елларда безгә дөньякүләм эшләү җитенкерәми.

Без бүген дә үз кыйблабызга тугры калып иҗат итәбез. Коллективтагы 23 артистыбыз да профессионаллар. Яңа репертуар өстендә һәрдаим эшләргә кирәклеген дә онытырга ярамый. Шуңа күрә дә кулда булган яңа (чи) материалны көн саен булмаса да, атнасына 1-2 тапкыр тыңлыйм. «Монысын эшләргә», «монысына игътибар итәргә» дип тамга салган 50ләп материал үз сәгате сукканны, кул тиеп, заманча чишелеш

**Илһам Шакиров та заманында: «Халыкның онытылган яки онытыла бара торган уен кораллары күп бит. Шуларны торгызып халыкка ирештерәсе иде. Бу инде үзенә күрә бер ренессанс (яңарыш), милли байлыгыбызны күрсәтү булыр иде», – ди.**

тапканны көтеп ята. Мин аларны үзем ничек күзаллыйм, шулай тәкъдим итәм. Нәрсәгә сөенәм, безнең шушы эшләгән җырларыбызны, биюләребезне үзешчән фольклор ансамбльләр сорап шалтыраталар. «Лимонад» яки «Балтырган»ны җырласак буламы, диләр. «Сеңлем, рәхәтләнеп җырла, мин сөенәм генә, рухи мирасыбызны барлау, баету һәм халкыбызга кайтару хакына бит бөтен эш-гамәлләребез», – дим.

**Фотолар Г. Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе архивыннан**

27 МАРТ – БӨТЕНДӨНЬЯ ТЕАТР КӨНЕ

# МӘКТӘПТӘ халык театры?!

Расиха ФАИЗОВА

**Хәтерләсәгез, Борис Щукин исемендәге театр институты ректоры Евгений Князев Дәүләт Советы утырышында мәктәпләрдә театр студияләре оештыру зарурлыгын федераль дәрәҗәдә якларга кирәк дип күтәреп чыккан иде. Бу идеяне «игътибарга лаек тәкъдим» буларак Россия Президенты Владимир Путин да хуплады. Республикада укыту-тәрбия эшендәге әлеге мөһим юнәлешне күпкә иртәрәк гамәлгә кертеп зур казанышлар, хәтта ХАЛЫК ТЕАТРЫ исемен яулаган коллективлар да юк түгел. Шуларның иң тәүгесе 2011 елның сентябрендә үк Казан шәһәренең «Лицей – инженер үзәге»ндә оешкан «Өмет» Халык театры. Биредә бер нәрсәне ассызыклап әйтергә кирәк: аралашу нигездә рус телендә барган мәктәптә татар театрының гөр килеп эшләп ятуы, тулы заллар җыеп спектакльләр куюы үзе бер могҗиза.**



«Кырларым-тугайларым» спектакле (Туфан Миңнуллин). Сулдан уңга: Гаделшина – Гөлназ Гыйләҗетдинова, Суфия – Нурсинә Мельникова, Закир Фәйрушин – Газинур Җиһаншин

## БУЙ ҖИТМӘГӘН ҖИРГӘ УЙ ҖИТӘ

Мәктәптә театр студиясе ачу – Татарстан Республикасының атказанган укытучысы, Россия Федерациясенең халык мәгарифе отличнигы лицейның директоры Венера Хәйретдинованың мәгариф үзәгендә эшләгәндә үк күңел түрендә бөреләнгән хыялы була. Яхшы ният эш башы дип ул профессионал артист, К. Тинчурин театры мәктәбен узып, ул чагында «Курай» радиосында эшләүче Раил Мөхетдиновка мөрәҗәгать итә һәм ялгышмый. Бер ай дигәндә мәктәптә «Сәләт» студиясе оешып, «Каракның бүреге яна» спектакле өстендә эшли башлыйлар. Бу гамәлен Венера Кәшбиевна әнисенә – Актаныш районында гомер итеп, авылда беренчеләрдән булып югары белем алган укытучы, һәвәскәр артист Хаҗәр ханым Шәйгәрданова рухына багышлый.

Балалар тәүге спектакль белән район бәйгесендә 1нче урынны яулагач, татар теле укытучылары да «без кемнән ким» дип кычырып әйтмәсәләр дә, педагоглар арасында да театр кирәк, оештырыйк дип режиссерны кодалый башлыйлар. Мондый карарга килгәнче билгеле инде татар теле һәм әдәбияты укытучысы мәрхүмә Лилия Мәгъфүр кызы Әхмәтшина иң тәүдә театр алдында торган бурычларны тирәнтен аңлап, укыту-тәрбия эшендәге үтемле юлларны барламый калмагандыр. Бу иң беренче чиратта ана теленең камиллеге, әдәбият белемен арттыру; милли тәрбия, милли сәнгатебезгә, гореф-гадәтләребезгә якынаю; дөньяны танып белүне, фикерләүне, аралашу даирәсен киңәйтү һәм әлбәттә инде иҗади мөмкинлекләргә юл ачу дигән сүз. «Әгәр дә театрның мәгънәсе күңел ача торган тамашада гына булса, бәлкем аңа шуның кадәр хезмәт салуның кирәге дә булмас иде», – дигән мәшһүр режиссер К. Станиславский. Чөнки үз системасы буенча театр мәктәбенә нигез салган педагог аның, актер һәм режиссер эше булу белән беррәттән, тамашачы өчен тормыш мәктәбе икәнлеген да күз уңында тоткан.

Раил Мөхетдинов җитәкчелегендә ел саен бер яңа спектакль белән сөендерә килгән ике театрның да уңышлары дәвамлы дияргә кирәк. Яшь артистлар, 2024 елда 187нче лицей базасында шөгыльләнеп, Булат Сәлаховның «Яратылмый калган ярлар» спектакле белән «Сәйяр» фестивалендә катнашып 84 мәктәп арасында Гран-прига – 1 млн сум (!) премиягә лаек була. Бу акчага театр өчен күп кенә костюмнар тектерелә һәм премиянең бер өлеше лицейда яңа оешкан Нәҗип Җиһанов музеен җиһазлауга тотыла.

## «ӨМЕТ» УҢЫШ ЮРЫЙ

Укытучыларны берләштергән «Өмет» труппасының беренче җимеше – Т. Миңнуллинның «Ай булмаса, йолдыз бар» әсәре буенча куелган спектакльнең сәхнәгә менүенә инде 15 елдан артык гомер узган. Репертуардагы ул спектакльне иң уңышлыларның берсе буларак әлегәчә искә алалар. Тамаша карарга килүче күпсанлы кунаклар арасында Г. Камал театрының мәшһүр артисткасы мәрхүмә Нәҗибә Ихсанова да булган. Тамашаны ул шул тиклем рухланып, илһамланып караган, хәтта: «Ниһаять, Совет районының да үз һәвәскәр театры булды. Исеме «Туфан театры» булсын әле!» – дигән тәкъдим белән чыккан. Труппа әлеге фикерне күтәреп ала алуын, тик нәкъ шул чорда Туфан Миңнуллин исеме Чаллы театрына бирелгәч бу ниятеннән кире кайта. Хәер, «Өмет» исеме дә бик килешә үзләренә, күп нәрсәләргә ымсындырып, бары уңыш юрап тора. Башлангыч мәлдә укытучыларның труппага әлегәсе килү теләге шул кадәр көчле була ки, кастингта Мәдинә роле өчен генә дә сигез кеше дәгъва белдерә.

Илдар Юзеевнның «Кыр казлары артыннан» спектакленең премьерасыннан соң труппа «Халык театры» статусы ала (2015 ел).

Әзербайҗан драматургының «Аршин Мал Алан» спектакленең дә үз тарихы. Беркайдан да тәрҗемәсен таба алмагач, Милли китапханәгә мөрәҗәгать итәләр. Бәхеткә каршы шунда Һидият Солтанов тәрҗемәсендәге бердәнбер китапны эзләп тапсалар да, шактый йончыган булу сәбәпле аны кулга тоттырмыйлар. Китапханә хезмәткәрләре әсәрнең күчермәсен ясау җаен таба. Дөрес, озак куандырмый бу спектакль. Уенда катнашучы артистларның кайберләре Мәскәүгә китү сәбәпле, репертуардан тиз төшә. Әмма үз кыйбласын билгеләргә өлгергән коллективның киләчәккә булган өметләренә ул гына киртә куя алмый. Казанның мәдәният сарайлары, Татарстан районнары, күрше республика

сәхнәләре белән генә чикләнмичә, мәктәптә каникуллар башлануга алар спектакльләрен Кыргызстан (Бишкек, Чулпан Ата), Алмания (Франкфурт-на-Майне), Нидерланд (Амстердам), Кырым (Симферополь, Бакчасарай) шәһәрләрендә дә күрсәтә. Узган ел труппа Берләшкән Гарәп Әмирлекләренең Дубай шәһәрендә булып кайтты. Кайда гына булмасыннар, спектакль тәмамлануга халык тиз генә китәргә ашыкмый. Әчкерсез аралашулар, искәрмәгән очрашулар хакында әле генә булгандай, берсен-берсе бүлдерә-бүлдерә искә ала укытучы-артистлар.

– Кырым нәрсәсе белән истә калды: кан кардәшләребезнең күбесе тамашага милли киемнәрдән килде, чыгышларыбызны тын да алмый карадылар. Минем, гомумән, андый тамашачыны күргәнем юк иде, – дип сөйли труппа җитәкчесе, режиссер Раил Мөхетдинов. – Әлегәчә: «Кадерле туганнар, Сез безгә килеп, күңелләребездә нур, өмет калдырып киттегез. Сезне сагынып яшибез», – дип хатлар язалар. Спектакльдән соң күз яшьләренә тыгылып татар сакалы җиткергән бер карт кына бабай сәхнәгә күтәрелде. «Мин әти-әниемнең кемнәр икәнен белмим. Алар Ленинград блокадасында һәлак булганнар, ә мине 1943 елда урамда үлем хәлендә йөргән кечкенә сабыйны бер мәрхәмәтле, олы йөрәкле татар гаиләсе табып алып, үзенә сыендырган. Мин татар тәрбиясе алып үскән кеше. Сез шулкадәр дә йөрәгемә якын: әти-әниемне күргәндәй булдым», – дип бөтенебезне тетрәндерде.

Алманиядә дә шул ук хәл кабатлана. Киткәндә үзләренең шәҗәрә китапларын бүләк итәләр. «Бу яулыкны, зинһар, әниеңә тапшыр әле, балам», – дип амәнәт итеп бүләк җибәрүчеләр дә булган. Килсәгез бөтен Ауропаны күрсәтер идек, дип язган хатлары 2023 елда имзаланган.

## УКЫТУЧЫЛАР – БОЛАЙ ДА АРТИСТ

Ни генә булмасын, рус телле мәктәптә озак еллар дәвамында татар театрының нәтиҗәле эшләп килүе зур мәртәбә.

30 ел математика укыткан Газинур Җиһаншин да инкярь итми моны. Чөнки үзе дә һич арттырусыз театрның умыртка баганасын тәшкил итүчеләрнең берсе. Пединститутта укыганда ук дүрт ел дәвамында ТАССРның 10 еллыгы исемендәге мәдәният йорты каршында эшләп килгән



**«Ай булмаса, йолдыз бар» спектакле (Туфан Миңнуллин). Сулдан уңга: Мәдинә Сафина – Эльза Яруллина, Гүзәл апа – Гүзәл Чернова, Мирзанур – Сирин Гасыймов**



**«Җәяүле Мәхмүт» (Мостай Кәрим) спектакленнән соң. Сулдан уңга: Инсаф – Раил Мөхетдинов, Шәрифә – Нурсинә Мельникова, Зәмзәгөл – Аделина Мельникова, Мәдинә – Инара Краснова, Мәхмүт – Газинур Җиһаншин, егет – Ранил Гобәйдуллин**

вузара студентлар театрында катнашып Рабит Батулланың «Кичер мине, әнкәй», Хәй Вахитның «Беренче мәхәббәт» спектакльләре белән хәтта Пермь краеның Барда районнары авылларында гастрольләрдә йөрергә туры килгән аңа.

– Үзләре дә сәхнә тоткач, укучыларыбызда да матур әдәби телдә сөйләшүгә ихтыяҗның арта баруын, спектакльләребезне бер кат «сүтеп җыеп» анализлауларын күреп, белеп торабыз. Бу сөендерә. Лицейның 100 кеше сыешлы залы һәрвакыт тулы була. Тамашаларыбызга татарча белмәгән әти-әниләр дә килә, андыйларга янәшәсендә утыручылар суфлер урынына тәрҗемә итеп бара, – ди ул.

Театр эшли башлаган көннән бүгенгәчә сәхнә тотучы математика укытучысы Гүзәл Чернова да коеп куйган артист.

– Гомер буе зур сәхнәләрдә уйнау турында хыялланып яшәдем. Театр коллиятенә бармый калуымның бердәнбер сәбәбе – җырларга кушсалар, булдыра алмам да, оятка калырмын дип курыктым. Бер чирканчык алгач, хәзер инде сәхнәсез яши дә алмам кебек. Труппадагыларның күбесе бала чактан артист булырга хыялланган кешеләр. Мин үзем коелып төшә торганнардан булмасам да, иң беренче сәхнәгә чыккан көнем аерым ачык хәтердә: куллар дерелди, аяклар калтырый, йөрәгем табан астына ук төшеп китте, – дип истәлекләрен барлап ала ул.

Лицейда «укытучы болай да артист бит инде ул» дигән фикерне дә берничә кешедән ишетергә туры килде. «Укытучылар – гомерлеккә мәктәптә калган артистлар», – дип моны атаклы педагог В. Сухомлинский да әйткән булган. Монда һәркем актерның авыр әйберне гадәти итеп, гадәти нәрсәне җиңел һәм җиңелне шәп итеп өйрәнергә тиешлеген күңеленә сеңдергән һәм барысы да рольләрне олы сәхнә таләпләренә җавап бирерлек итеп башкарырга тырыша. Раил Фәрхәтович режиссер – актер форматында эшләргә, сүз ятлау белән генә мавыкмыйча, партнерыңны ишетергә, ишеткәнеңне бәяләргә, шуннан соң гына аңа җавап бирергә кирәклеген төшендерә. Бер сүз белән әйткәндә Сирин Гасыймов, Роберт Харрасов, Гөлназ Гыйләҗетдинова, Гөлнара Әхмәтова кебекләр биредә мәктәптән чыкмый гына да артист булып, Тукайча әйтсәк, «күңелдәге дәртне уятырлык итеп» илһамланып иҗат итүдән тәм табалар.

**Фотолар театрның фотоархивыннан**

# Җылы да, йомшак та

Гүзәл ИСМӘГЫЙЛЕВА



**Җыелышып йон язу, җеп эрләү, бәйләм бәйләү, ягъни «орчык өмәсе»; киез басу белән бәйле «тула өмәсе» кебек йолаларыбыз инде күптән тарихта калган гамәлләр кебек тоелыр бәлкем.**

Борынгыдан килгән, вакыт белән сыналган әлеге кул эшләрен, заманча технологияләр кулланыштан кысырыклап чыгарып, халык хәтереннән үк җуйдырырга уйлаган иде булса кирәк. Юк икән бит. Әле дә авылларда кич утырып йоннар эрләп махсус хәрби операциядәге солдатларга оекбашлар, бияләйләр бәйлиләр.

Киез басучылар да юк түгел. Дөрес, XIX йөзнең икенче яртысында акрынлап кулланыштан чыкса да, республиканың Азнакай, Бөгелмә, Әлмәт кебек көньяк-көнчыгыш районнарында һөнәрчелекнең бу төре сакланып кала. Аеруча Бөгелмә районы Татар Димскәе авылы һөнәрчеләре арасында киң таралган була. Шул исәптән, булачак рәссам Дефак Рәхмәтуллинның әтисе Гатаулла да коеп куйган осталарның берсе саналган авылда. Оясында ни булса, очканында шул булыр ди. Әлеге кәсепнең бөтен нечкәлекләрен күреп-белеп, әтисе баскан киез келәмнәрнең матурлыгын кечкенәдән күңеленә сеңдереп үскән егет 70нче еллар ахырында үзе дә чын-чынлап әлеге эшкә тотына.

Җирле осталардан «ала киез», «сырмак» технологияләрен өйрәнә, төсле композицияләргә өстенлек бирә. Гомеренең көзәнәчә төркиләр тарихын, мифологиясен тирәнтен өйрәнгән рәссамның тырышлыгы, үҗәтлеге белән халык-авыз иҗатына нигезләнеп эшләнгән киез келәмнәр, паннолар; татар, болгар милли бизәкләре шәхси йортларга гына түгел җәмәгать биналарына да үтеп керә. Юкка гына республикада һөнәрчелекнең бу төрен торгызып, көч-кодрәт биреп үстереп җибәрүне нәкъ менә ир-ле-хатынлы Дефак Гатаулла улы (1951-2007) һәм Роза Халит кызы Рәхмәтуллиннарның исеме белән бәйләмиләр.

Табигый чималга игътибар арту тула басу белән кызыксынуны алга таба да арттырачак әле. Соңгы вакытта киез эшләнмәләрнең шактый популярлашуы да шуны раслый. Кукмара итекләренә генә күз салсак та, аларның да заман белән бер аяктан атлавын күрербез. «Кукмара итекләре» Бөтенроссия халык иҗаты фестиваль-ярминкәсе дә буш урында барлыкка килмәгән.

2009 елда Казан Кирмәнендә зурлап уздырылган «Төрки дөньяда киез сәнгате» форумы да безгә тирәнгә киткән



тамырларыбызның көч-куәтен ачып салды. Киез, тула басуның югары сәнгать дәрәҗәсенә күтәрелеп, чын-чынлап икенче сулыш алуын, аның мәдәни-тарихи әһәмияте артуын раслады. Кайчандыр күчмә халыкларны җәен эсседән, җил яңгырдан, кышын зәмһәрир суыклардан саклаган киез – бүген гамәли сәнгатьтә үз урынын көннән-көн ныграк яулый бара. Татарстанда 2020 елдан бирле киез сәнгатендәге үзенчәлекләрне, технологияләрне тирәнтен үзләштереп, камилләштереп фәнни нигездә өйрәнеп иҗат итүче рәссамнарны берләштергән «Киез Нур» төбәк иҗтимагый оешмасы эшләп килә.

*– Элеккеге һөнәрчеләр киезне, гадәттә, җәй көне ишегалдында, су буйларында баскан булсалар, хәзер аны өй, остаханә шартларында эшлиләр. Камзул, итәк, башмак, эшләпә, оекбаш кебек кием-салымнар, keләмнәр, намазлыклар, паннолар – һәммәсен басалар. Без инде ике тапкыр (2021, 2024 еллар) Президентның мәдәни инициативалар фонды грантына ия булдык,* – ди «Киез Нур»-ның алыштыргысыз җитәкчесе, Татарстан Республикасы Фәннәр Академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының өлкән фәнни хезмәткәре, сәнгать фәннәре кандидаты, Россия сәнгать белгечләре ассоциациясе әгъзасы Людмила Шкляева.

– Киез басу үтә дә мавыктыргыч, табигать үзе кулга тоттырган шөгыль. Кулга йогып, ятып торган табигый материалның сихри көченә төшенеп, шуны укучыларыма да җиткерәсем килгән иде. Теләгемә ирештем. Дөньяны тагын да җылырак, җетерәк, кызыграк итүдән тәм табып эшлим. Киезне басасың басасың да эш ахырында кулыңда әзер әйбер күреп сабый бала кебек куанасың, – дип 5нче сәнгать мәктәбе укытучысы **Нелли Ильясова** өстәлгә төрледән-төрле йон йомгакларын җәеп сала.

Сарык йоныннан чәчәкләр (йолдызлар) ясау барышында бу эшнең нечкәлекләренә без нәкъ менә Нелли белән бергәләп төшенәчәкбез.

## Кирәкле материаллар:

**Сарык йоны (киез басу өчен көзге йон алына. Гадәттә табигый ак, соры, сирәк кенә кара, көрән төсләрдәге һәм кызыл, зәңгәр, сары кебек ачык төсләргә манылганнары да кулланыла); сабынлы кайнар су; кайчы, капрон челтәр, өстәлгә җәяр өчен бүртмәчле полиэтилен.**

## Эш барышы

Беренче карашка чәчәк ясау кыен түгел, әмма ул бездән сабырлык таләп итәчәк. Нәрсә генә эшләргә тотынсаң да, аны булачак үлчәменнән зурырак итәргә кирәк, чөнки йон кипкәндә 20-30 процентка утыручан була. Нинди төсләргә өстенлек бирүне алдан ук чамалап куярга кирәк. Әзер чәчәкләрне йон свитерга, береткага, башлыка, бияләй яки шарфка төсле җепләр белән тегеп куярга мөмкин булачак. Без исә үзебез эшләгән чәчәкләрне киез келәмгә «сибеп» чыгачакбыз һәм махсус энә ярдәмендә чәнчеп-чәнчеп беркетеп куярбыз.

**1.** Иң элек йонны бик әз-әз генә чеметеп суырып алып, аларны чәчәк яки йолдыз рәвешенә килерлек итеп өсте-өстенә берничә кат салып чыгабыз. Төсләр бер-берсе белән ярашып килсен. Үзәген сары яки аерылып торган (контраст) башка төстән куйсаң яхшы.



**2.** Булачак чәчәгебез өстенә челтәр каплап аз гына сабынлы су (ул кул пешмәслек булырга тиеш) белән чылатып чыгабыз һәм дулкын сыман өзек-өзек кул хәрәкәтләре ясап кырыйдан үзәккә таба баса башлыйбыз. Йон киезләнеп, челтәргә кереша башлаганчы басып-басып ышкыйбыз.



**3.** Йонның челтәргә керешкәнен сизгәннән соң, челтәрне ачып, булачак чәчәкне сак кына аннан аралап (кубарып) алабыз да икенче ягын әйләндереп җай гына шул ук эшне кабатлыйбыз, ягъни челтәр каплап сул ягын басабыз.



**4.** Күз явын алырлык «йомшак» чәчәкләр килеп чыкты, шулай бит. Үзе бер чәчәк аланы диярсең. Кипкәннән соң аларның һәркайсына үз урынын табып урнаштырырга кирәк.



Автор фотолары

# Боз озату

## (Мәктәпкә әзерлек төркемендә бәйрәм)

**Авыл урамы, йорт алдында утыргыч куелган. Шунда ук читтәрәк кое бурасы күренеп тора. Авыл читендә елга күренеп тора (зәңгәр тукымадан ясалган). Аның өстендә пенопласттан киселгән бозлар «ага». Каршы өйдән ир бала чыга һәм күршесенең тәрәзәсенә кага.**

**1нче бала.** Хәзер чыгам, ни булды? *(чыгып, капка төбенә утыра).*

**2нче бала.** Нишләп өйдә утырасың, елгада боз кузгала! Әйдә, боз озатырга, су буена. Мин хәзер югары очка барып, хәбәр салып киләм. Син, әйдә, түбән очка чап. Боз киткәнен күрми калмасыннар тагын.

*Балалар әзерләнеп чыкканчы, бер бала яз турында шигырь сөйли. (Шул арада өйләр читкәрәк этеп куела, берничә агач куеп су буе күренеше ясала, утыргыч әзерләнә.)*

**3нче бала.** Шигырь укый.

**ЯЗ КИЛӘ**

*Мөнир Мазунов*

*Көннәр аяз, күктә алсу*
*Нур сибеп кояш көлә.*
*Җиргә тама көмеш тамчы –*
*Сагынып көткән яз килә.*

*Әйтегезче, кайсы вакыт*
*Яздагыдан ямьлерәк?*
*Кыш айларын да яратам,*
*Әмма яз күңеллерәк.*

*Көннәр җылы, күктә алсу*
*Нур сибеп кояш көлә,*
*Җәйге шатлык, күзгә бәхет*
*Яз белән бергә килә.*

*Татарча көй яңгырый. Малайлар, кызлар икешәрләп, өчәрләп су буена җыела.*

**4нче бала.** Карагыз, карагыз! Боз ныклап торып кузгалды бит!

**5нче бала.** Әбием, шул бозлар белән төрле авырулар, күңелсез вакыйгалар да агып китә, ди.

**6нчы бала.** Исегездәме, узган ел боз өстенә учак ягып җибәргәннәр иде. Быел да шулай булырмы икән?

**1нче бала.** Әнә, бакча башында Назыйм абыйларның кыштан калган саламнары бар,



хәзер мин бик тиз генә бер кочак салам алып киләм.

**7нче бала.** Бу эшкә өлкәннәрдән башка тотынмавың яхшы. Дуслар, әйдәгез кара-каршы басыйк та «Башмакчы» булыйк.

***Җырлы-биюле «Башмакчы» уены.***

*Балалар түгәрәк ясап басалар. Өлкәннәрдән берәрсе уенны оештыручы була. Ул, кулына бер башмак алып (башмак уйнаучы балаларның аяк үлчәменнән зуррак булырга тиеш), уртага баса.*

**Җырлый:**
Төрле һөнәр беләбез,
Матур итеп тегәбез;
Асыл төсле җепләр белән
Башмак башын чигәбез.

*(Балалар аңа каршы, түгәрәк буйлап йөреп, җыр җырлыйлар)*

Әй, башмакчы, башмакчы,
Үзең оста такмакчы.
Син җырлама такмагын,
Бир кияргә башмагын.

*(Уен беткәндә таягына таянган бабай керә)*

**Бабай.** Балалар, кайчаннан бирле күңел ачасыз, сез җырлаганны тыңлап, боз озатуны гына түгел, җилкәләренә чиккән кулъяулыклар салган егетләрне җырлый-җырлый армиягә озатулар искә төшеп китте. Бик күңелле була торган иде солдатка озатулар.

**5нче бала.** Бабай, сез боз озатканда нинди уеннар уйный идегез ул? Берәрсен безгә дә өйрәт әле.

**Бабай.** Әнә, тегендәрәк үскән ак каенны күрәсезме? Без шунда кадәр йөгереп куышлы уйный торган идек. Куып тота алмаса да, тоттырса да уенчыга җәза, бирешле иде. Парлашып басыгыз да, йөгереп карыйк.

***«Куышлы» уенын уйнау***

Марат Алсуны куып тота алмады. Аңа нинди җәза бирәбез?

**Бөтенесе бергә.** Берәр тизәйткеч әйтсен!

**Марат.** Сыерчык, сыерчык,
Нинди матур сызгырчык!

**Бөтенесе бергә.** Әйдәгез, тагын уйныйбыз. Бу юлы кемнәр йөгерә?

*(Уен бернichә тапкыр кабатлана. Җәза буларак, яз турында шигырь яки җыр башкарыла)*

**6нчы бала.** Ә мин тапкырга табышмак әйтәм...
Ак юрганымны алып куйдым,
Яшел юрганымны җәеп куйдым.

*(кыш фасылын яз алыштыра)*

**Бабай.** Ә сез беләсезме, балалар, елгаларның ни рәвешле боздан ачылуын; язның, кышның, җәйнең ничек килүен күзәткән әби-бабаларыбыз, элек еш кына халык сынамышларына таянып эш иткән. Дөнья булгач, аларның сезгә дә кирәге чыгып куюы бар. Ягез әле, кайсыгыз нинди сынамыш белә?

**1нче бала.** Елгалар язын боздан тиз әрчелсә, ашлык уңар.

**2нче бала.** Су ташуы куәтле булса, ашлык яхшы булыр.

**3нче бала.** Язын иртә күк күкрәсә, ел яңгырлы булыр.

**4нче бала.** Яз көне елгаларда су артмаса, ашлык уңмас.

**5нче бала.** Яз көне елга кырыйларында боз калса, ашлык уңмас.

**Бабай.** Афәрин, балалар! Мин кайтыйм инде. Сез дә озак тормагыз. Без боз озатканда еллар тыныч килсен, басуларда уңыш мул булсын, начар чирләр, кайгы-хәсрәт килмәсен дип теләкләр әйтә-әйтә кулъяулыкларга берәр әйбер төйнәп елгага агыза торган идек. Сез дә борынгыдан килгән йолаларны онытмагыз.

Әйдәгез әле... *(теләкләр телиләр)*

**1нче бала.** Рәхмәт сиңа, бабай. Кызлар, малайлар, әйдәгез тагын бер генә уен уйнап алабыз да, аннан таралышырбыз.

*(«Уфа-Чиләбе», «Шома бас» уеннарының берсен уйнап алу)*

**Эльвира ШӘРИПОВА,**
**Актаныштагы 3нче балалар бакчасында өлкән тәрбияче**

**Автор фотосы**

**C:\Users\Dilyara\Downloads\Экият иле (мелодия) (2).pdf**

# Әкият иләндә

Эльмир Низамов көе
Резедә Гобәева сүзләре




*Без бүген әкият илендә*
*Дөньяның иң матур җирендә!*
*Кем генә юк монда, карале:*
*Аю да, бүре дә, тиен дә!*

*Курыкмыйм бүредән мин бүген,*
*Аюга кул биреп күрешәм!*
*Кытыклыйм Шүрәле абзыйны,*
*Куянга уйнап туп тибешәм!*

*Төлкедән курыкмый куяннар,*
*Диюгә атланган Таң батыр!*
*Тычканнар кочаклый песине –*
*Әкият дөньясы – киң, матур!*

*Хыялдай мәһабәт зур Сарай,*
*Бик килә тик синдә каласы!*
*Көн саен могҗиза тудыра,*
*Сер тулы әкият дөньясы!*

**28 ФЕВРАЛЬ – БӨТЕНДӨНЬЯ ТАТАР АШЛАРЫ КӨНЕ**



# Ашлы өйдә *бәрәкәт бар*

**Әгәр исән булса, бу көнне РСФСРның атказанган сәүдә хезмәткәре, Ленин һәм Халыклар дуслыгы орденнары кавалеры, СССРның Халык хуҗалыгы казанышлары күргәзмәсендә кулинар хезмәтләре өчен алтын медаль алган татар халык ашлары белгече, ашчы Юныс Әхмәтҗановка 99 яшь тулган булыр иде.**

Бөтендөнья татар ашлары көне әлеге легендар шәхескә зур хөрмәт күрсәтү йөзеннән аның туган көненә туры китереп тәгаенләнгән.Татарның аш-суын дөнья күләмендә танытуда аның өлеше гаять дәрәҗәдә зур. Авылдан-авылга йөреп, халкыбызның милли ризыкларын әзерләү рецептларын туплап, эшкәртеп 17 китап чыгара ул.

«Пешекче – артист ул, кунагының күңелен табу өчен, аңа нәкъ сәхнәдәгечә сәнгать остасы булырга туры килә. Йөзендә һәрчак елмаю булсын. Усалланып йөрүче кеше тәмле аш пешерә белми ул. Пешекче – табиб. Аңа кешеләрнең сәламәтлеге тапшырылган. Пешекче – рәссам. Аның ашы тәмле генә түгел, бик матур да булырга тиеш. Пешекче философ та, педагог та, сәгатьләр буе утлы плитә янында торучы металлург та», – ди торган булган ул аш-су остасының төрле яктан килгән кеше булуына басым ясап.

Ул табын түренә чыгарган, дөньяга таныткан ризыклар бихисап. Казан мантые да шуларның берсе. Мантыйга дигән фаршка бәрәңге турап салсаң, ул күбрәк тә чыга, очсызрак та була, дип акчасыз студентлар мәнфәгатен дә кайгырткан Юныс ага.

**Фото Ю. Әхмәтҗановның гаилә архивыннан**


# КАЗАН *мантые*



## КИРӘКЛЕ ИНГРЕДИЕНТЛАР

**Камыр өчен:**
500 грамм он,
100 миллилитр су,
1-2 данә йомырка,
0.5 чәй калагы тоз

**Эчлек өчен:**
700 грамм фарш,
2-3 данә бәрәңге,
300 грамм башлы суган,
тәменчә тоз, кара борыч,
зира







**1.** Камыр өчен кирәкле ингредиентларны кушып камыр басабыз һәм пленка белән каплап 15 минутка ял итәргә куябыз.




**2.** Эчлек әзерлибез. Суганны, бәрәңгене вак кына итеп шакмаклап турыйбыз, төменчә тоз, кара борыч, зира салып фарш белән бергә болгатабыз.

**3.** Камырны юка итеп җәябез һәм 8-10 сантиметрлы шакмаклар ясап кисәбез һәм һәрберсенең уртасына берәр аш кашыгы эчлек салып чыгабыз.



**4.** Камырның башта кара-каршы якларын, аннан «колакларын» ябыштырабыз.








**5.** Мантый савытын сыек май белән майлап, мантыларны тезәбез һәм газ плитәсендә 40-45 минут пешерәбез. Пешеп чыккач майлап, каймак яки шулпа белән табынга бирәбез.

**Ашларыгыз тәмле булсын!**

**Р. Исмәгыйлова фотолары**

# Бергәләп бизибез!



# Истәлекле даталар
2026

## АПРЕЛЬ

**2 апрель**

Актёр, ТАССРның халык, РСФСРның атказанган артисты Евгений Андриянович Кузинның тууына 90 ел (1933-2004)

**2 апрель**

75 ел элек «Алтынчәч» операсы өчен (Муса Җәлил либреттосы) композитор Нәҗип Җиһановка СССРның Дәүләт премиясе бирелә (1948)

**5 апрель**

Рәссам-проектлаучы Рәшит Лотфулла улы Фәттаховка 70 яшь (1953)

**10 апрель**

140 ел элек Бакчасарай шәһәрендә төрки-татар телендә «Тәрҗеман» газетасы нәшер ителә башлый (1883-1918)

**11 апрель**

Гамәли бизәлеш рәссамы Александр Сергеевич Маяковка 75 яшь (1948)

**14 апрель**

Рәссам, педагог Мария Михайловна Васильеваның тууына 120 ел (1903-1964)

**15 апрель**

Театр белгече, библиограф Һәнүз Котдус улы Мәхмүтовның тууына 90 ел (1933-1996)

**19 апрель**

Гамәли бизәлеш рәссамы, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының Б. Урманче исемендәге премиясе лауреаты Анатолий Николаевич Егоровка 75 яшь (1948)

**21 апрель**

Режиссёр, педагог, ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Равил Рәхим улы Тумашевның тууына 100 ел (1923-2016)

## МАЙ

**1 май**

Гамәли бизәлеш сәнгате рәссамы Дамир Әхмәт улы Илдаровка 75 яшь (1948)

**5 май**

Рәссам, график Флүс Нурулла улы Төхбәтуллинга 75 яшь (1948)

**11 май**

Монументаль бизәлеш сәнгате рәссамы, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының Б. Урманче исемендәге премиясе лауреаты, Татарстан Республикасының халык рәссамы Игорь Николаевич Башмаковның тууына 80 ел (1943-2012)

**16 май**

Татарстанның халык артисты, Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты Дамирә Нәҗмиҗан кызы Кузаеваның тууына 75 ел (1948-1993)

**20 май**

Актёр, режиссёр, Татарстан Республикасының халык артисты Айдар Садри улы Хафизовның тууына 80 ел (1943-2020)

**30 май**

Әдәбият тәнкыйтьчесе, шагыйрь, ТАССРның атказанган мәдәният хезмәткәре Мөдәррис Харис улы Вәлиевнең (Салих Маннапов) тууына 70 ел (1953-2020)

## ИЮНЬ

**13 июнь**

Рәссам Радик Вакыйф улы Минһаҗевка 60 яшь (1963)

**15 июнь**

Актриса, Татарстанның халык артисты, Республиканың М. Җәлил исемендәге премиясе лауреаты Зөлфирә Сафи кызы Зариповага 70 яшь (1953)

**15 июнь**

Рәссам Әнвәр Камил улы Сәйфетдиновка 60 яшь (1963)

**15 июнь**

Гамәли бизәлеш рәссамы Фәридә Мирзанур кызы Сәхабетдиновага 60 яшь (1963)

**20 июнь**

Рәссам Илдус Миңнулла улы Насретдиновка 90 яшь (1933)

**25 июнь**

Хормейстер, педагог, Татарстанның халык артисты Венера Хәсән кызы Гәрәеваның тууына 80 ел (1943-2020)

**27 июнь**

Шагыйрь Фәннур Шәйхенур улы Сафинның тууына 75 ел (1948-1992)

**30 июнь**

Язучы, Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре, М. Горький исемендәге әдәби премия, Г.Р. Державин исемендәге Республика премиясе лауреаты Нонна Николаевна Орешинаның тууына 90 ел (1933-2015)

**https://kitaphane.tatarstan.ru сайтыннан алынды**





**Кадерле укучыларыбыз!**
2026 елның беренче яртыеллыгы өчен «Түгәрәк уен» альманахына республикабызның барлык элемтә бүлекләрендә, яисә «Почта России» сайты аша (https://podpiska.pochta.ru Индекс ПА 183 яисә «Тугарак уен» дип җыярга) онлайн да язылырга мөмкин.

**Индексыбыз – ПА 183**
**Өч айга язылу бәясе – 294 сум 07 тиен**
**Ярты елга язылу бәясе – 588 сум 14 тиен**

БЕРГӘ БУЛЫЙК, ДУСЛАР!